Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 151/о номерлы боерыгы белән расланды

**Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе) тарафыннан проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы, шул исәптән экспертлар тарафыннан бәяләү уздыру, буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) 49 статьясындагы $3^4$ өлешенең 1-5 пунктларында күрсәтелгән объектларга карата (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карарының (алга таба – 145 номерлы карар) 2 пунктының «б» пунктчасындагы икенче-бишенче һәм сигезенче абзацларда күрсәтелгән объектлардан тыш), шулай ук, проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә карата экспертиза (дәүләт яки дәүләтнеке булмаган) уздыру мәҗбүри булып торса яки РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 2, 3 һәм $3^1$ өлешләре нигезендә мәҗбүри булып тормаса һәм мөрәҗәгать итүче проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен дәүләт экспертизасына юллау турында карар кабул итсә, төзелешне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру, капиталь төзелеш объектын сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен башкару күздә тотылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, башка объектларга карата да;

төзелешне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру, капиталь төзелеш объектын сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен башкару күздә тотылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, – Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендә яки муниципаль

милектә торган объектларына карата (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясының 1 өлешенең 5[1] пунктында күрсәтелгән субъектлардан тыш);

төзелешне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру, капиталь төзелеш объектын сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен башкару күздә тотылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, – төзелеше, үзгәртеп корылышы, капиталь ремонты, сүтелеше, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен башкару Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр оештырган юридик затларның яки устав (җыелма капиталында) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары өлеше 50 проценттан артып киткән юридик затларның акчасын җәлеп итеп тәэмин ителә торган объектларга карата (145 номерлы карарның 2 пунктындагы «б» пунктчасының икенче-бишенче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән объектлардан тыш);

капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау планлаштырыла торган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, – 145 номерлы карарның 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелмәгән объектларга һәм үзләренә карата дәүләт экспертизасын үткәрү федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында федераль башкарма хакимият органнары һәм оешмалар вәкаләтенә кертелмәгән объектларга карата;

капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру күздә тотылган җир кишәрлекләренең берсе Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъекты территориясендә төзү, үзгәртеп кору өчен күздә тотылган объектларга карата (145 номерлы карарның 2 пунктының «б» пунктчасының икенче - бишенче һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән объектлардан тыш);

капиталь төзелеш объектын үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру күздә тотылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан очракта, бер Россия Федерациясе субъекты территориясендә үзгәртеп кору күздә тотылган, Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан объектларга карата (145 номерлы карарның 2 пунктының «б» пунктчасындагы икенче-бишенче һәм сигезенче абзацларында күрсәтелгән объектлардан тыш).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: техник заказчы, төзүче яки аларның берәрсе тарафыннан вәкаләт бирелеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән зат, шулай ук, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 1[1] һәм 1[2] өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнүләрен башкарган һәм (яки) проект документларын әзерләүне тәэмин иткән зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче). Мөрәҗәгать итүче исеменнән юридик зат җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ышаныч кәгазе яисә үзенең шәхесен таныклаучы документлар нигезендә эш итә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү.

1.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләргә мәгълүмат җиткерү Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

Дәүләт хезмәте Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең адресы: 420073, Россия, ТР, Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 22.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең урнашу урыны адресы: 420054, Россия, ТР, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 125.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 8.00 башлап 17.00 кадәр, җомга: 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш: 12.30 башлап 13.45 кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, көн саен, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эш сәгатьләрендә.

«Железнодорожная» тукталышына кадәр җәмәгать транспорты белән килү: 23, 25, 43, 56, 72, 77 номерлы автобуслар.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе бинасына керү кертү кәгазе һәм (яисә) шәхес таныклаучы документ буенча гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең белешмә телефоннары:

директор: 8 (843) 272-04-94;

директорның беренче урынбасары: 8 (843) 520-70-50 (өст. 401);

директор урынбасары: 8 (843) 520-70-50 (өст. 401);

эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе: 8 (843) 272-56-84 (өст. 230);

экспертиза идарәсе җитәкчесе: 8 (843) 241-02-19 (өст. 235);

документларны кабул итү бүлеге: 8 (843) 272-56-84 (өст. 205);

бәяләмәләр белән эшләү һәм аларны бирү бүлеге: 8 (843) 272-65-14 (өст. 213);

коммерция хезмәтләре күрсәтү бүлеге: 8 (843) 520-70-50 (өст. 450);

бухгалтерлык исәбе, хисаплылык һәм финанс бүлеге: 8 (843) 272-65-60 (өст. 248);

кадрлар бүлеге: 8 (843) 241-02-14 (өст. 241).

1.3.2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайты адресы - http://www.minstroy.tatarstan.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре);

Министрлыкның рәсми сайтында; Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе рәсми сайтында (http://gosekspertiza.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм

порталында (http://gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Хезмәтләр күрсәтү реестры реестры);

2) Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә телдән (шәхсән яисә телефон буенча) мөрәҗәгать иткәндә;

3) Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

4) визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

5) «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең (алга таба – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны) ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта (шәхсән яисә телефон буенча).

1.3.4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында, Хезмәтләр күрсәтү реестрында һәм Республика порталында урнаштырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламент (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

Бердәм порталда, Республика порталында Хезмәтләр күрсәтү реестрында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең «Интернет» челтәрендәге рәсми

сайтларында, Хезмәтләр күрсәтү реестрында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

КФҮ АМС – күпфункцияле үзәкләр эшчәнлегенә ярдәм итүнең автоматик мәгълүмат системасы;

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать. Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Регламентның 4 нче, 4.1 кушымталарында китерелгән;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт

экспертизасы (алга таба – дәүләт экспертизасы).

2.2. Башкарма хакимият органы исеме

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе;

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып дәүләт экспертизасы бәяләмәсе тора.

Инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турындагы бәяләмәдән гыйбарәт.

Проект документларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе булып бәяләмә тора:

проект документларының техник регламентларның, санитар-эпидемиологик таләпләргә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгый куркынычсызлык таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы якланганлык таләпләренә, төзүченең яисә техник заказчының проект йөкләмәсенә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында, – проект документларының ярашлылыгын бәяләү гамәлгә ашырылган очракта;

смета бәясенең төгәллеге (уңай бәяләмә) яки төгәл булмавы (тискәре бәяләмә) турында, – смета бәясенә тикшерү үткәрелгән очракта.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында мөрәҗәгать итүченең Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетына (алга таба – шәхси кабинет), күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе мөрәҗәгать итүчедән әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документларны алган көннән өч эш көне эчендә аларны тикшерә. Тапшырылган документларның закон таләпләренә туры килгән очракта, гариза теркәлә һәм электрон мәгълүматлар базасына кертелә.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчедән документлар алынган көннән башлап өч эш көне эчендә аңа, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспетизасы уздыруга, проект документларына һәм инженерлык эзләнү

нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү күләмен исәпләп, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе ягыннан имзаланган килешү проекты яисә проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен тапшырылган документларны кабул итүдән дәлилле баш тарту (белдерү) тапшырыла (җибәрелә) һәм әлеге документларга карата аларны карамыйча калдыру турында карар кабул ителә.

2.4.3. Төзелешен, үзгәртеп корылышын яки капиталь ремонтын финанслау Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетлар акчасын, дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата дәүләт экспертизасы килешү төзелгәннән соң уздырыла башлый һәм Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгәч (тапшырылгач) тәмамлана.

Башка капиталь төзелеш объектларына карата дәүләт экспертизасы Мөрәҗәгать итүче килешү нигезендә дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү кертелүен раслый торган документларны тапшырганнан соң уздырыла башлый һәм Мөрәҗәгать итүчегә Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе тапшырылганнан (җибәрелгәннән) соң тәмамлана.

2.4.4. Проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү вакыты 30 эш көненнән артмаска тиеш. Дәүләт экспертизасы 30 эш көне дәвамында үткәрелә:

проект документлары әлеге экспертизага җибәрелгәнчегә кадәр – дәүләт экспертизасына җибәрелгән инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә карата;

проект документлары яки проект документлары һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү өчен каралган күләмдә проект документларына.

Капиталь төзелешнең торак объектларына карата, шул исәптән кертеп-янкорма итеп төзелгән торак булмаган биналары булганнарына карата да, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы 20 эш көне дәвамында үткәрелә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән сроклар мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча килешүдә билгеләнгән тәртиптә иң күбе 20 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин.

Дәүләт экспертизасын үткәрелгәндә, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә килешүдә билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә, ләкин дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты тәмамланганчы кадәр 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, оператив рәвештә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.5. Экспертлар белән эш уздырганда Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән башлап өч эш көне эчендә аларны тикшерә һәм мөрәҗәгать итүчегә,

экспертлар белән эшләгән өчен түләүне исәпләп, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе ягыннан имзаланган түләүле хезмәтләр күрсәтү килешүенең проектын (әлеге Регламентка 1.1 кушымта) тапшыра яки әлеге документларга карата аларны караусыз калдыру турында карар кабул итела.

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү өчен бирелгән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый карар турында ул документлар Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе кергән көннән соң ике эш көне эчендә хәбәр ителә.

Эксперт тарафыннан бәяләү эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү төзелгәннән соң һәм эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешү нигезендә түләү кертелгәнлегенраслый торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылганнан соң башлана.

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү эше мөрәҗәгать итүче Нигезләмәнең 17(3) пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң башлана һәм эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмне мөрәҗәгать итүчегә җибәрү (тапшыру) белән төгәлләнә.

Эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе Нигезләмәнең 17(4) пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган көнне әзерләнә башлый һәм капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәреп (тапшырып) тәмамлана.

2.4.6. Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллеккә бәя бирүне үткәрү вакыты Нигезләмәнең 17(3) пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң иң күбе 10 эш көне. Әлеге срок Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан ярашлылык бәясенә тәкъдим ителә торган проект документларына үзгәрешләр проект документларының ике һәм аннан да күбрәк бүлегенә кертелгән очракта арттырыла ала, ләкин иң күбе 10 эш көненә кадәр генә.

Эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү (тапшыру) чоры Нигезләмәнең 17(4) пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән гаризаны Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә тапшырган көннән башлап 15 эш көненнән һәм Нигезләмәнең 17(4) пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән документларны Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә тапшырган көннән башлап 35 эш көненнән артык була алмый.

Эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү бер елга төзелә. Эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү вакыты чыгарга кимендә 30 эш көне калгач мөрәҗәгать итүче эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүнең гамәлдә булу чорын арттыру турында Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый хәбәр җиткерелгән очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе мондый килешүнең гамәлдә булу чорын бер елдан артмаган чорга

озынайту турында мөрәҗәгать итүче белән төзелгән эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүгә өстәмә килешү әзерли.

2.4.7. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, шул исәптән эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча да, Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрында реестр номеры беркетелгән көннән соңгы бер эш көне эчендә, ләкин дәүләт экспертизасын уздыру срогының соңгы эш көне узганчы кертелә.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

Дәүләт экспертизасы уздыру өчен гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар түбәндәгечә кабул ителә ала:

1) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә турыдан-туры шәхси кабинет аша;

2) күпфункцияле үзәк һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә электрон документлар рәвешендә күпфункцияле үзәк аша;

3) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, электрон формада;

Гариза (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы) әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документларны теркәп, шул исәптән мәгълүмати модельләштерү технологияләрен (ТИМ-технологияләрен) кулланып әзерләнгән проект документлары да, билгеләнгән форма буенча тапшырыла.

Проект документлары («Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 13 пунктының «г» пунктчасында каралган очракта, проект документларының бер өлеше) һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына кабат (ике һәм аннан күбрәк тапкыр) түбәндәге очракларда җибәрелә:

а) тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәннән соң;

б) уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә каралмаган үзгәрешләр кертелгәндә;

в) уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә каралган үзгәрешләр кертелгәндә.

Кабат дәүләт экспертизасы уздыру өчен мөрәҗәгать итүче Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә әлеге Регламентның 3 нче кушымтаында

күрсәтелгән документларны теркәп, билгеләнгән формада (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы) гариза, шул исәптән мәгълүмати модельләштерү технологияләрен (ТИМ-технологияләрен) кулланып әзерләнгән проект документларын тапшыра.

2.5.1. Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәргән оешмага эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү төзү максатында түбәндәге документлар тапшырыла:

эксперт тарафыннан бәяләү өчен килешү төзү турында гариза (әлеге Регламентка 4.1 кушымта) һәм мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче булмаган очракта), аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне (алга таба – килешү) төзү, үзгәртү, үтәү, өзү вәкаләтләре махсус килешенгән булырга тиеш.

2.5.1.1. Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясыныэ $3^9$ өлешендә билгеләнгән таләпләргә тәңгәллеген бәяләү (алга таба – эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү) уздыру өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

а) проект документларының үзгәрешләр кертелгән бер өлеше;

б) проект документларына кертелгән үзгәрешләр тасвирламасы белән белешмә;

в) төзүче яисә техник заказчының проектлау биреме (аңа үзгәрешләр кертелгән очракта);

г) проект документларын әзерләү буенча эшләрне башкаручы зат анда әгъза булып торган архитектура-төзелеш проектлавы өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан үзгәртелгән проект документларын төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасында гамәлдә булган өземтә (Россия Федерациясе законнары нигезендә проект документларын әзерләү буенча эшләр башкаручы затның архитектура-төзелеш проектлавы өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителгән очракта), шулай ук проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә, техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнүләрен һәм (яки) проект документларын әзерләүне тәэмин иткән затка тапшыруны раслый торган документ.

2.5.1.2. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 310 өлешендә каралган очракта, эксперт тарафыннан бәяләү барышында проект документларына кертелгән үзгәрешләргә дәүләт экспертизасы (алга таба – эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы) уздыру өчен эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешү гамәлдә булган чор кысаларында түбәндәгеләр тапшырыла:

а) эксперт тарафыннан бәяләү барышында проект документларына кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсендә капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясе билгеләнгән тәртиптә дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) капиталь төзелеш объектына карата кабул ителгән, капитал салуларны гамәлгә ашыруга

бюджет ассигнованиеләре бирү турындагы карарда билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору бәясенә туры килгән очракта, – эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирү турында гариза, анда эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бирелгән бәяләмәләр турында мәгълүмат күрсәтелә;

б) эксперт тарафыннан бәяләү барышында проект документларына кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсендә капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясе үзгәргән һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт милкендәге (муниципаль милектәге) капиталь төзелеш объектына карата кабул ителгән, капитал салуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре бирү турындагы карарда билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору бәясенә туры килмәгән очракта, – эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирү турында гариза, анда эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бирелгән бәяләмәләр, бирелә торган бәяләмәдә төзелеш, үзгәртеп коруның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендәге нәтиҗәләрне чагылдыру кирәклеге турында мәгълүмат, шулай ук эшләрнең физик күләмнәре, конструктив, оештыру-техник үзгәрешләр һәм эксперт тарафыннан бәяләү барышында проект документларына кертелгән башка чишелешләр нәтиҗәсендә үзгәртүгә дучар ителгән өлешендә смета нормаларына карата расланган, алар турындагы мәгълүматлар смета нормативларының федераль реестрына кертелгән смета нормативларын, федераль берәмлек бәяләрен, шулай ук аларның аерым өлешләрен, һәм (яки) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү турында гариза тапшыру датасына билгеләнгән төзелеш ресурсларына смета бәяләрен исәпкә алып үзгәртелгән смета күрсәтелә.

Нигезләмәнең 27 пунктының «а» пунктчасында каралган бәяләүне уздыру һәм 27 пунктның «б» пунктчасында каралган тикшерүне уздыру өчен 145 номерлы карарның 2 пунктының «б» пунктчасының сигезенче абзацында каралган капиталь төзелеш объектларының проект документларын төрле дәүләт экспертизасы оешмаларына җибәрү рөхсәт ителми.

Гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә шәхси кабинет, Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ аша тапшырыла.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури

булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы оешмалар карамагында булган һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар (белешмәләр) таләп ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт экспертизасына тәкъдим ителгән проект документларын һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен кире кагу нигезләре:

а) проект документларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләре составы һәм алар эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары белән расланган Проект документлары бүлекләре составы һәм алар эчтәлегенә карата таләпләр турында нигезләмәдә билгеләнгән таләпләр нигезендә мондый документлар составына кертелергә тиешле бүлекләрнең булмавы;

б) проект документлары бүлекләренең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы 13 өлеше нигезендә билгеләнгән проект документлары бүлекләренең эчтәлеге таләпләренә туры килмәве;

в) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнгән составка һәм формага туры килмәве;

г) проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле булган, Нигезләмәнең 13-16 пунктларында күрсәтелгән барлык документларның да тапшырылмавы, шул исәптән материаллар составының, формасының һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының 6 өлеше нигезендә билгеләнгән материаллар составына, формасына һәм нәтиҗәләргә туры килмәве яки инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең булмавы (проект документлары инженерлык эзләнү нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына юллангannan соң дәүләт экспертизасына җибәрелгән булса);

д) дәүләт экспертизасына тапшырылган проект документларының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән зат тарафыннан әзерләнүе;

е) нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына җибәрелгән инженерлык эзләнүләренең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән таләпләргә туры килми торган зат тарафыннан башкарылуы;

ж) дәүләт экспертизасы дәүләт экспертизасы уздыру буенча башка оешма тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиешле булса;

з) гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль

закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документларны тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.7.1. Эксперт тарафыннан бәяләү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

а) әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында каралган документларны тапшырмау;

б) әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында каралган гаризаның вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылуы;

г) тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

д) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

е) гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон формада билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылуы;

ж) 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;

Экспертлар белән эш итү кысаларында тәңгәллеккә бәяләү үткәрү өчен бирелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

а) әлеге Регламентның 2.5.1.1 пунктында күрсәтелгән, эксперт тарафыннан бәяләү өчен кирәкле барлык документларны да тапшырылмавы;

б) документларны Нигезләмәнең 18 пункты нигезендә электрон формада тапшырыла торган документларның форматына карата Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган таләпләрне бозып тапшыру;

в) Нигезләмәнең 17(3) пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру датасына Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсендә үзләренә карата эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмә яки эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелмәгән, әлеге капиталь төзелеш объекты буенча элегрәк тапшырылган документларның карау өлешендә торуы;

г) гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документларны тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, мондый документлар Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә алынган көннән башлап ике эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына яки, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап,

күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү өчен тапшырылган документларны карамыйча калдыру турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

документлар 145 номерлы карарның 2 пунктындагы «к» һәм «л» пунктчаларында каралган таләпләрне яисә Нигезләмәнең 18 пункты нигезендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла торган документлар форматына карата расланган таләпләрне бозып тапшырылган очракта.

Эксперт ярдәме нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктында күрсәтелгән, эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү өчен кирәкле документларны тапшырмау;

б) гаризаның вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

в) эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен биргәндә исәпкә алынырга тиешле, эксперт тарафыннан бәяләү барышында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бирелгән уңай бәяләмәнең (уңай бәяләмәләрнең) булмавы;

г) эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү турындагы гаризада мондый бәяләмәне биргәндә исәпкә алынырга тиешле проект документлары үзгәрешләренә карата төгәл булмаган мәгълүматларның күрсәтелүе;

д) әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаларны тапшыру датасына әлеге капиталь төзелеш объекты буенча үзләренә карата эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмә яки эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелмәгән, эксперт тарафыннан бәяләү турындагы тиешле килешү кысаларында элегрәк тапшырылган документларның Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсендә каралу өлешендә торуы.

Югарыда күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе гариза алынган көннән башлап өч эш көне эчендә эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирү турында гариза биргән мөрәҗәгать итүчегә әлеге

карар кабул ителгән көнне, аны кабул итү мотивларын күрсәтеп, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан әлеге карар турында хәбәр ителә.

Дәүләт экспертизасы үткәрү өчен тапшырылган документларны карамыйча калдыру турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында, аны кабул итү мотивларын күрсәтеп, хәбәр ителә.

Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

1. Проект документларына дәүләт экспертизасы, шул исәптән эксперт тарафыннан бәяләү, мөрәҗәгать итүче акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт экспертизасы өчен түләү дәүләт экспертизасы нәтиҗәләренә бәйсез рәвештә башкарыла.

3. Капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен башкарыла торган инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү күләме Нигезләмәнең 51-58 пунктлары нигезендә билгеләнә.

Смета бәясен тикшерү күләмендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрмичә һәм ярашлылыкны бәяләмичә генә гамәлгә ашырыла торган проект документларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәясенең 20 проценты күләмендә, смета бәясен тикшерү күләмендә проект документларына дәүләт экспертизасы уздыру өчен документлар тапшырылган көнгә исәпләнгән түләү алына.

Дәүләт экспертизасын кабат үткәргән өчен беренчел дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләменең 30 проценты күләмендә, дәүләт экспертизасын кабат үткәрү турында килешү төзү датасына исәпләнгән түләү алына.

Нигезләмәнең 45(1) пунктында күрсәтелгән очракта, дәүләт экспертизасын кабат үткәрү өчен түләү, беренчел дәүләт экспертизасын үткәрү өчен дәүләт экспертизасын кабат үткәрү турында килешү төзү датасына исәпләнгән түләү буларак исәпләнә.

Элегрәк тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләре элегрәк дәүләт экспертизасына җибәрелмәгән проект документлары белән берлектә дәүләт экспертизасына юлланган очракта, мондый дәүләт экспертизасын уздырган өчен түләү, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә беренчел дәүләт экспертизасын уздырган кебек, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын кабат уздыру турында килешү төзегән датага исәпләп чыгарылган түләү кебек исәпләнә.

Әгәр капиталь төзелешнең торак объектларына карата дәүләт экспертизасын кабат үткәрүгә документлар тискәре бәяләмә алган көннән башлап 10 эш көне

эчендә тапшырылган булса, дәүләт экспертизасын кабат үткәргән өчен түләү алынмый.

Эксперт тарафыннан бәяләү өчен эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү төзү датасына исәпләнгән беренчел дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләменең 30 проценты күләмендә түләү алына. Эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүне озайтканда, түләү күләме беренчел дәүләт экспертизасын үткәрү өчен эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешү озайтыла торган датага исәпләнгән түләү күләменең 30 процентын тәшкил итә.

Төзүче тарафыннан проект документларының «Капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау сметасы» бүлеге проект документларының башка бүлекләрен әзерләмичә генә әзерләнгән очракта, капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлауның смета бәясен тикшерү өлешендә проект документларына, күпфатирлы йортлардан (күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәттән) тыш, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздырмыйча һәм проект документларының тәңгәллеген бәяләмичә генә гамәлгә ашырыла торган дәүләт экспертизасын уздырган өчен капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау буенча смета бәясенең бер проценты күләмендә, ләкин кимендә 24 мең сум түләү, шулай ук өстәмә хак салымы алына.

Капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлауның смета бәясе 10 млн. сумнан артып китсә (өстәмә хак салымыннан башка), төзәтү коэффициентларын исәпкә алып, түбәндәге күләмдә түләү алына:

| Капиталь ремонтның смета бәясе (өстәмә хак салымыннан ү), млн. сум | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|
| 10 башлап 30 кадәр | 0,35 |
| 30 башлап 100 кадәр | 0,23 |
| 100 башлап 200 кадәр | 0,10 |
| 200 башлап 500 кадәр | 0,09 |
| 500 артык | 0,08 |

Күпфатирлы йортларга (күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә) капиталь ремонт буенча смета бәясен тикшерү күләмендә проект документларына инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрмичә һәм проект документларының тәңгәллеген бәяләмичә үткәрелә торган дәүләт экспертизасын уздырган өчен 24 мең сум күләмендә түләү, шулай ук өстәмә хак салымы алына.

Дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләмен исәпләгәндә, Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса, өстәмә кыйммәткә салым суммасы исәпкә алына.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыны кабул итүне (мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүне) көтү вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

Гаризаны кабул итү һәм теркәү аны электрон документ рәвешендә тапшырганнан соң автомат рәвештә башкарыла.

Гаризаны кабул итү һәм теркәү мөрәҗәгать итүче тарафыннан аны тапшырган көнне автомат рәвештә башкарыла.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын

тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

9) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм әлеге пунктның 3-6 пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтүдән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга инвалидларның үтеп керә алуын тәэмин итү, инвалидларга инвалидлар өчен бинаның үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүкән бүтән каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламент бозылуга нигезле шикаятьләрнең булмавы.

Мөрәҗәгать итүченең Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе яки күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән үзара бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә бер мәртәбәдән артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең бүлек белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.

Мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда, КФҮ дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы.

Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяли ала.

2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча да (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта), һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр

Проект документлары һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре, шул исәптән мәгълүмати модельләштерү технологияләрен (ТИМ-технологияләрне) кулланып әзерләнгән проект документлары, шулай ук проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә экспертиза уздыру өчен кирәкле башка документлар электрон формада тапшырыла.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә рәсми мөрәҗәгать тапшыру өчен кабул итүгә язылу Республика порталыннан файдаланып гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында, КФҮ урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә танылканган документларны һәм мәгълүматны шәхси кабинеттан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында шәхси кабинетта белешмәләр алырга;

г) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында шәхси кабинетта алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Электрон формада тапшырылган документлар оешма җитәкчесе яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль законда каралган көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана.

2.17. Мөрәҗәгать итүчеләрне күпфункцияле үзәктә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Республика порталы аша, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

телефон номеры;

электрон почта адресы (ихтыяры буенча);

кабул итүнең теләнгән датасы һәм вакыты.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, унбиш минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

### 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү бәясен билгеләү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында килешү төзү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

6) күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең теркәлгән бәяләмәсен төзү һәм (расланган күчермә) бирү;

7) дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү

9) дәүләт хезмәтен кабат күрсәтү;

10) техник хатаны төзәтү.

Мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентка 4 нче, 4.1 кушымталарда күрсәтелгән форма буенча әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар пакеты (алга таба – документлар исемлеге) белән Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә гаризасы (рәсми мөрәҗәгате) дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау өчен нигез булып тора.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу

өчен шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече Мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече Мөрәҗәгать итүчене дәүләт хезмәтен алу предметы буенча консультацияли, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бланк тапшыра һәм зарурлык булганда гариза бланкысын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша яки күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзаланганнан соң имзаланган гаризаны Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына сканер аша кертә;

электрон формада тапшырылган документларны яки документларның сканер аша уздырылган электрон үрнәкләрен Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрү өчен әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә

тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланышлар системасы аша Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан документларның комплектлылыгын карау.

Гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларны мөрәҗәгать итүче электрон документ рәвешендә шәхсән яисә ышанычлы заты аша Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырылган көннән соңгы өч эш көне эчендә документларны кабул итү белән шөгыльләнүче Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә.

Эксперт тарафыннан бәяләү турында гариза тапшырылган көннән соңгы ике эш көне эчендә документларны кабул итү белән шөгыльләнүче Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгечләре, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны теркәү.

3.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның комплектлылыгын тикшерү.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәясен билгели яисә проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыру өчен тапшырылган документларны кабул итүдән нигезләнгән баш тарту (белдерү) җибәрелә яисә әлеге документларга карата аларны карамыйча калдыру турында карар кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта, мондый карар турында Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Дәүләт экспертизасы уздыру өчен тапшырылган документларны карамыйча калдыру турындагы карар әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта кабул ителә, Мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында, аны кабул итү мотивларын күрсәтеп, хәбәр ителә.

Әлеге очракларда мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү электрон формада, шул исәптән Бердәм порталдан файдаланып та, гамәлгә ашырыла.

Электрон рәвештә тапшырылган документлар (дәүләт экспертизасы үткәрү турындагы гаризадан тыш) кимендә өч ай дәвамында сакланырга тиешле.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы үткәрү өчен гаризаны теркәү һәм дәүләт экспертизасы бәясен билгеләү, яисә мөрәҗәгать итүчегә проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү өчен тапшырылган документларны кабул итүдән нигезле баш тарту (белдерү) җибәрү, яисә мөрәҗәгать итүчегә аларны карамыйча калдыру турында карар кабул итү турында белдерү җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт экспертизасы уздыру турында гариза алынган һәм кирәкле документлар тапшырылган көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Җаваплы – Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең бәясен билгеләү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә килешү төзү.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе белгече дәүләт экспертизасы бәясен билгели һәм, дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү күләмен исәпләп, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе ягыннан имзаланган килешү проектын мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Килешүнең киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән. Эксперт тарафыннан бәяләү турында килешүнең киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентка 1.1 кушымтада күрсәтелгән.

Хезмәт күрсәтү өчен түләүче катнашында өч яклы килешү төзелергә мөмкин. Өч яклы килешү төзелгән очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе –

мөрәҗәгать итүченең гаризасы буенча хезмәтләр күрсәтү, мөрәҗәгать итүче – аларны кабул итү, ә түләүче хезмәтләр өчен түләү җаваплылыгын үз өстенә ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза алынган көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт экспертизасы уздыруга килешү проектын җибәрү.

Җаваплы – Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсе белгече.

3.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү (бирүдән баш тарту) турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.6.1. Килешүгә кул куелгач һәм дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү кертелүен тикшергәннән соң, бүлекнең җаваплы белгече бер эш көне дәвамында проект документларын әйдәп баручы Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе экспертына тапшыра.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүчедән проект документларында кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең исәп-хисапларын, шулай ук инженерлык эзләнү материалларын таләп итәргә хокуклы. Әлеге исәп-хисаплар һәм материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле мөрәҗәгать алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

Проект документларына капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау буенча эшләрнең смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү өлешендә дәүләт экспертизасы уздыру өчен Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе шулай ук мөрәҗәгать итүчегә исәпләп чыгару өчен смета нормалары билгеләнмәгән чыгымнарның смета бәясенә кертелгән өстәмә исәпләмә нигезләүләрен яисә проект документларында каралган конструктив, технологик һәм башка чишелешләрне, шулай ук чыгымнары смета бәясенә кертелгән эшләрне башкару кирәклеген раслый торган инженерлык эзләнү материалларын, тапшыру кирәклеге турында нигезләнгән мөрәҗәгать юлларга хокуклы. Әлеге нигезләүләр һәм материаллар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле мөрәҗәгать алынганнан соң биш эш көне узганчы тапшырыла.

3.6.1.1. Эксперт тарафыннан бәяләү турында имзаланган килешү булган очракта һәм эксперт тарафыннан бәяләү өчен түләү кертелгәндә, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсенең җаваплы белгече документларны кабул итә һәм, алга таба документларны әйдәп баручы экспертка тапшыру өчен, тапшырылган документларны эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында әлеге Регламентның 2.5.1.1 пунктына туры килүен бәяләү өчен тикшерә.

Эксперт тарафыннан бәяләү тапшырылган бирелгән документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый карар турында ул документлар алынган көннән соң ике эш көне эчендә хәбәр ителә.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны кабул итү һәм әйдәп баручы экспертка тапшыру, яисә, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр итү.

3.6.2. Нигезләмәнең 35 пункты нигезендә, дәүләт экспертизасын үткәрү барышында проект документтарында һәм (яки) инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләрендә бәяләмә әзерләргә мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (белешмәләрнең, тасвирламаларның, исәпләмәләрнең, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы яисә тулы булмавы) ачыкланган очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр итә.

Капиталь төзелешнең торак объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырылганда җитешсезлекләрне бетерү срогы мөрәҗәгать итүче тарафыннан белдерү алынган көннән башлап иң күбе биш эш көне тәшкил итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар килешү имзаланган һәм дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү кертелгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: локаль эксперт бәяләмәсе төзү, мөрәҗәгать итүчегә җитешсезлекләр турында белдерү җибәрү.

3.6.3. Әгәр ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләт экспертизасы уздыру барышында юкка чыгару мөмкин булмаса яисә мөрәҗәгать итүче билгеләнгән чорда аларны бетермәсә, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе алга таба дәүләт экспертизасы үткәрүдән баш тартырга һәм фактта күрсәтелгән хезмәтләрне түләп, килешүне вакытыннан алда өзү мәсьәләсен күтәрергә хокуклы, бу хакта кабул ителгән карар сәбәпләрен күрсәтеп, Мөрәҗәгать итүчегә язмача хәбәр итә.

3.7. Күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең теркәлгән бәяләмәсен төзү һәм (расланган күчермә) бирү.

3.7.1. Ачыкланган җитешсезлекләргә җаваплар һәм үзгәртелгән документлар алынганнан соң алар дәүләт экспертизасы бәяләмәсен төзү өчен Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең җаваплы экспертына тапшырыла.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең җаваплы эксперты законнар нигезендә уңай (тискәре) бәяләмә (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) төзи һәм раслау өчен аны Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директорына тапшыра.

Эксперт дәүләт экспертизасын үткәрә һәм квалификация аттестатында (квалификация аттестатларында) күрсәтелгән эшчәнлек юнәлеше (юнәлешләре) буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен әзерли.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән һәм дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашкан затлар тарафыннан әзерләнә һәм имзалана, һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан раслана. Электрон формада әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашкан экспертлар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры

яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан бәяләмәне көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап раслана.

Кул куелгач һәм расланганнан соң, дәүләт экспертизасы бәяләмәсе эшчәнлек башкару тәртибендә теркәү өчен Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлеге белгечләренә тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар капиталь төзелешнең торак объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырылганда Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документлар тапшырылган көннән башлап биш эш көне эчендә (яисә, башка очракларда, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җитешсезлекләре бетерелгән, үзгәртелгән документлар тапшырылган көннән башлап 10 эш көне эчендә) гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы үткәрүдә катнашкан экспертлар тарафыннан имзаланган һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры тарафыннан ресланган һәм теркәү өчен тапшырылган уңай (тискәре) дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

3.7.1.1. Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясыныэ $3^9$ өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең әйдәп баручы эксперты тугыз эш көне дәвамында проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең тәңгәллеген бәяли. Әлеге срок Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан ярашлылык бәясенә тәкъдим ителә торган проект документларына үзгәрешләр проект документларының 2 һәм аннан да күбрәк бүлегенә кертелгән очракта арттырыла ала, ләкин иң күбе 10 эш көненә кадәр генә.

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәсе булып проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитар-эпидемиологик таләпләргә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсе таләпләренә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз файдалану таләпләренә, сәнәгый куркынычсызлык таләпләренә, электр энергиясе системаларының һәм электр энергиясе объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата таләпләргә, объектның террорчылыкка каршы яклану таләпләренә, төзүченең яки техник заказчының проектлау биременә, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлешенә ярашлы булуын да кертеп, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүен (уңай) яки туры килмәвен (тискәре) раслау турындагы нәтиҗәләрне үз эченә алган бәяләмә тора.

Нигезләмәнең 17(4) пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гариза бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре

буенча, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлеше белән ярашуын, проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитария-эпидемиология таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы яклангану таләпләренә, проектлауга төзүче яисә техник заказчы бирəменә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелә.

Нигезләмәнең 17(4) пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлеше белән ярашуын, шулай ук төзүнең, үзгәртеп коруның смета бәясен дөрес билгеләү яки дөрес билгеләмәү турында да, проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитария-эпидемиология таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы яклангану таләпләренә, проектлауга төзүче яисә техник заказчы бирəменә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелә.

Бәяләү нәтиҗәсе әлеге Регламентка 6.1 кушымта нигезендә рәсмиләштерелә.

Бәяләүне үткәргәннән соң, бәяләмә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсесенең әйдәп баручы эксперты тарафыннан, раслау, теркәү һәм мөрәҗәгат итүчегә бирү өчен, эксперт эшчәнлеген оештыру идарәсенә җибәрелә.

Бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмәне раслау, теркәү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү бер эш көне дәвамында башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 2.5.1.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләү нәтиҗәләре буенча теркәлгән бәяләмәне мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.7.1.2. Әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктының «а» яки «б» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша электрон документ

рәвешендә әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктының «а» яки «б» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаны тапшыра.

Гаризаны кабул итү һәм теркәү аны электрон документ рәвешендә тапшырганнан соң автомат рәвештә башкарыла.

3.7.1.3. Экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен әзерләү, мөрәҗәгать итүчегә экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү (тапшыру), капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен җибәрү (тапшыру)

3.7.1.4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе эксперты әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән гариза Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә тапшырылган көннән башлап 12 эш көне эчендә һәм әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән документлар Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә тапшырылган көннән башлап 32 эш көне эчендә экспертлык эшчәнлеген уздыра һәм квалификация аттестатында күрсәтелгән эшчәнлек юнәлеше (юнәлешләре) буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен әзерли

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе (алга таба – дәүләт экспертизасы бәяләмәсе) әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелгән форма нигезендә әзерләнә һәм проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләре әзерләү хокукына аттестатланган һәм дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашкан затлар тарафыннан имзалана һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан раслана. Электрон формада әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экспертизасын үткәрүдә катнашкан экспертлар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан бәяләмәне көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап раслана.

Кул куелгач һәм расланганнан соң, дәүләт экспертизасы бәяләмәсе эшчәнлек башкару тәртибендә теркәү өчен проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлеге белгечләренә тапшырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган һәм расланган бәяләмә.

3.7.2. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлегенең вәкаләтле хезмәткәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе расланган көннән соңгы эш көне дәвамында мөрәҗәгать итүче тапшырган бәяләмәне һәм документларны экспертиза уздыру өчен Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына (алга таба – Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестры) кертә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе турында белешмәләрне Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертү, дәүләт экспертизасы бәяләмәсен Капиталь төзелеш

объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрында теркәү (дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номеры бирү) мәгълүмат системасы («Төп дәүләт экспертизасы идарәсе» федераль автоном учреждениесе (алга таба – Төп дәүләт экспертизасы идарәсе) операторы тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына керткән көннән соңгы эш көне узганчы гамәлгә ашырыла.

Тапшырылган документларда «Төп дәүләт экспертизасы идарәсе» ФАУ тарафыннан дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номерын беркетү һәм мондый бәяләмә турында белешмәләрне Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертү мөмкинлеген бирми торган җитешсезлекләр ачыкланган очракта, проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлеге хезмәткәре мәгълүмат системасы операторыннан баш тарту алынган көннән башлап бер эш көне эчендә тиешле кисәтүләрне бетерә, шулай ук Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына документларның билгеләнгән комплектын яңадан тапшыруны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләмә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан расланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсе турында мәгълүматларны Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертү, дәүләт экспертизасы бәяләмәсен Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрында теркәү (дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номеры беркетү).

3.7.3. Электрон документ формасындагы дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрында реестр номеры беркетелгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча, ләкин дәүләт экспертизасын уздыру срогының соңгы эш көне узганчы, шәхси кабинетка кертелә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү электрон формада башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт экспертизасы бәяләмәсе Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен шәхси кабинетка кертү яки Мөрәҗәгать итүчегә тапшыру.

3.7.4. Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирүне күпфункцияле үзәк хезмәткәре

тарафыннан Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәве, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8. Дәүләт экспертизасы эшен формалаштыру.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт экспертизасы эше ачыла. Дәүләт экспертизасы эшләре даими саклана торган архив документларына карый. Аларны юкка чыгару, шулай ук төзәтү һәм (яисә) аларда булган документларны алу рөхсәт ителми.

а) эксперт бәяләве нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы үткәрү (беренчел һәм кабат), дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү турында гариза;

б) килешү һәм эксперт бәяләве турында килешү күчермәләре;

в) килешү нигезендә экспертиза үткәрү өчен җәлеп ителгән оешмалар һәм (яисә) белгечләр тарафыннан ясалган нәтиҗәләрне үз эченә алган документлар;

г) дәүләт экспертизасы бәяләмәләре (беренчесе һәм кабат), эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәләре;

д) дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле булган, Россия Федерациясе законнарында һәм Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан билгеләнгән башка төрле документлар (документларның күчермәләре).

Әгәр дә проект документлары һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре, шулай ук әлеге Регламентта каралган башка төрле документлар электрон рәвештә тапышырылган булсалар, дәүләт экспертизасы эше электрон рәвештә алып барыла һәм анда дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырылган барлык документлар кертелә. Электрон рәвештә тапшырылган документларга төзәтмәләр кертү һәм аларны юкка чыгару рөхсәт ителми.

3.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Бирелгән бәяләмәләр реестрын алып бару һәм Бирелгән бәяләмәләр реестрыннан мәгълүмат бирү Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлыкның «Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын аып бару һәм бу Реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибе турында» 2007 елның 2 июлендәге 186 номерлы боерыгы белән җайга салына.

Мондый бәяләмә турындагы белешмәләр Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгәнчегә кадәр капиталь төзелеш объектларының проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен бирү рөхсәт ителми.

3.10. Дәүләт хезмәтен кабат күрсәтү.

Проект документлары (Нигезләмәнең 13 пунктының «г» пунктчасында каралган очракта, проект документларының бер өлеше) һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре дәүләт экспертизасына кабат (ике һәм аннан күбрәк мәртәбә) җибәрелә:

а) тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәннән соң;

б) уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә каралмаган үзгәрешләр кертелгәндә;

в) уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документларына мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының $3^8$ өлешендә каралган үзгәрешләр кертелгәндә.

Кабат дәүләт экспертизасы әлеге Регламентның 3.1-3.10 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасын кабат үткәрү турындагы гаризага проектның баш инженеры тарафыннан имзаланган белешмә теркәлә, анда проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә кертелгән үзгәрешләр тасвирлана.

Электрон формада һәм кәгазь документ рәвешендә әзерләнгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен югалткан очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге бәяләмәнең расланган күчермәсен алырга хокуклы. Таныкланган күчермә бирү язма мөрәҗәгать алынганнан соң җиде эш көне эчендә түләүсез нигездә башкарыла.

3.11. Техник хатаны төзәтү.

Элегрәк бирелгән бәяләмәдә җибәрелгән техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүгә бәйле рәвештә дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында теркәлгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән), техник хатасы булган дәүләт экспертизасы бәяләмәсен һәм мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслый торган документны теркәп гамәлгә ашырыла.

Техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яки почта аша (шул исәптән электрон почта аша) Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә яисә Бердәм портал, Республика порталы яки күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.11.1. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм теркәүгә ала;

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры гаризаны караганнан соң, җитәкче дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү турында яки үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап хаты әзерләү турында резолюция имзалый, башкару өчен җаваплы затны билгели.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән, башкару өчен җаваплы белгечкә тапшырылган гариза.

3.11.2. Җаваплы белгеч:

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директорының дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертү яки үзгәрешләр кертүдән баш тарту турындагы боерыгы проектын әзерли;

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры боерыгы проектын Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директорына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза алынган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директорына килештерү өчен юнәлдерелгән боерык проекты.

3.11.3. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе директоры дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык раслый. Имзаланган боерык җаваплы белгечкә җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура проект раслау өчен килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү яки дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында боерык.

3.11.4. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерык чыгарылган очракта, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең җаваплы белгече, Бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестры дәүләт мәгълүмат системасының реестр бүлеге өлешендә проект әзерли һәм аны Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрын алып бару һәм аларда булган белешмәләрне һәм документларны бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 февралендәге 115/пр номерлы боерыгы (алга таба – Тәртип) белән расланган Тәртипнең 32 пунктының «а» пунктчасы, 34 һәм 35 пунктлары таләпләре нигезендә реестрны алып баруның мәгълүмат системасында терки.

3.11.5. Техник хатаны төзәтү Тәртипнең 29-40 пунктлары таләпләре нигезендә «Россиянең баш дәүләт экспертизасы» ФАУ тарафыннан башкарыла.

3.11.6. Бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестры дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр керткәннән соң, җаваплы белгеч рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында җавап бирә (җибәрә).

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы төзәтелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан шушы Регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның үтәлүен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшереп тору эше тиешле административ процедураны башкару өчен җаваплы булган зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы тикшереп тору Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе

вазыйфаи затларның шушы Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе актлары нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавына тикшерүләр уздырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затлары (хезмәткәрләре), КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр хезмәт күрсәтелүгә бәйле рәвештә Министрлыкка тапшырыла, дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яки монополиягә каршы органга бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүмат тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый

актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең рәсми сайты (http://gosekspertiza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк җитәкчесенең һәм (яки) күпфункцияле үзәк хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затының (хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затының (хезмәткәренең), күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләре яисә аларның күчермәләре.

5.5. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе, Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итмичә кире кагуына яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта – аны теркәү көненнән соң биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш итеәә торган форма

Түләүле хезмәтләр күрсәтү килешүе

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе (Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе), алга таба «Башкаручы» дип исемләнеп, ___________________________ нигезендә гамәл кылучы _______________ йөзендә, бер яктан, һәм ______________________ нигезендә гамәл кылучы ______________________ йөзендә, алга таба «Заказчы» дип исемләнеп, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип исемләнеп, әлеге килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

1. Килешүнең предметы

1.1. Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрүгә әлеге килешү (алга таба – килешү) шартлары буенча Башкаручы Заказчы гаризасы буенча «_______________________» дәүләт экспертизасын үткәрү (алга таба – хезмәтләр күрсәтү, дәүләт экспертизасы) бурычын, ә Заказчы бу хезмәт күрсәтү өчен түләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләрен кабул итеп алу бурычын үз өстенә ала.

1.2. Проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе булып бәяләмә тора.

Инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турындагы бәяләмәдән гыйбарәт.

Проект документларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе булып бәяләмә тора:

проект документларының техник регламентларның, санитар-эпидемиологик таләпләргә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгый куркынычсызлык таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы якланганлык таләпләренә, төзүченең яисә техник заказчының проект

йөкләмәсенә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында, – проект документларының ярашлылыгын бәяләү гамәлгә ашырылган очракта;

смета бәясенең төгәллеге (уңай бәяләмә) яки төгәл булмавы (тискәре бәяләмә) турында, – смета бәясенә тикшерү үткәрелгән очракта.

## 2. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәтләргә түләү һәм исәп-хисап ясау тәртибе

2.1. Экспертиза бәясе Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

2.2. Бу килешүнең 1.1 пункты нигезендә Заказчы дәүләт экспертизасы үткәрү бәясен Башкаручыга түләү күләменә (килешүнең 1 нче кушымтасы) туры китереп түли, аның күләме – ____________________ тәшкил итә, шул исәптән 20%лы ставка буенча өстәмә хак салымы – ________________________.

Дәүләт экспертизасы үткәрү барышында проект документларының, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең күләме арткан очракта һәм (яисә) карала торган проект документлары буенча проект-эзләнү эшләренең бәясе үзгәртелгәндә, килешү буенча экспертизаның бәясе тәгаенләштерелергә тиеш.

2.3. Хезмәткә түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе нинди булуга бәйсез рәвештә түләнә.

2.4. Заказчы әлеге килешү имзаланган көннән башлап 5 эш көне эчендә хезмәтләр күрсәтү бәясенең 100%ы күләмендә аванс түләү бурычын үз өстенә ала. Башкаручы аванс суммасы килгән көннән башлап исәпләнә торган 5 календарь көннән соңга калмыйча, Заказчыга күрсәтеләчәк хезмәтләр өчен счетка аванс түләве буенча счет-фактура бирә.

2.5. Счетны түләү көне булып акча чараларының Башкаручының исәп-хисап счетына килгән, банк өземтәсендә расланган көн санала.

2.6. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе нигезендә акча чараларын өченче зат тарафыннан Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты

3.1. Проект документларына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү вакыты 30 эш көненнән артмаска тиеш.

Капиталь төзелешнең торак объектларына карата, шул исәптән кертеп-янкорма итеп төзелгән торак булмаган биналары булганнарына карата да, проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы 20 эш көне дәвамында үткәрелә.

Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә 20 эш көненә озайтылырга мөмкин.

Башкаручы хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда тәмамларга һәм Заказчыга эш нәтиҗәсен – бәяләмә бирергә хокуклы.

3.2. Төзелешен, үзгәртеп корылышын яки капиталь ремонтын финанслау Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетлар акчасын, дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы килешү төзелгәннән соң уздырыла башлый һәм Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгәч (тапшырылгач) тәмамлана.

Башка капиталь төзелеш объектларына карата проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы Мөрәҗәгать итүче килешү нигезендә дәүләт

экспертизасы уздырган өчен түләү кертелүен раслый торган документларны тапшырганнан соң уздырыла башлый һәм Мөрәҗәгать итүчегә Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе тапшырылганнан (җибәрелгәннән) соң тәмамлана.

3.3. Дәүләт экспертизасы уздыру буенча хезмәт күрсәтү Яклар тарафыннан имзаланган дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне тапшыру-кабул итү акты белән раслана (алга таба – «Акт»).

3.4. Әгәр Заказчы Актка кул куюдан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән көннән соңгы 5 (биш) календарь көн эчендә язмача баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән вакытларда дәлилле баш тарту тапшырылмаса, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә нинди дә булса ризасызлыкларсыз күрсәтелгән дип санала. Дәлилле баш тартуда әлеге килешүдә каралган бурычлар чиген уздырмый торган кисәтүләр булырга тиеш.

## 4. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Дәүләт экспертизасын үткәрү барышы турында мәгълүмат алу һәм Башкаручыга зарури аңлатмаларны, өстәмә белешмәләрне һәм документларны тапшыру.

4.1.2. Заказчының Башкаручы сайтындагы шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, өстәмә документларны электрон документ формасында Башкаручыга тапшыру.

Оператив рәвештә Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документларына үзгәрешләр кертү.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән килешүне имзалау һәм Башкаручыга кайтару, әлеге килешү нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен түләү.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, Акт буенча күрсәтелгән хезмәтне кабул итү, имзалау һәм уңай яисә тискәре бәяләмә рәсмиләштерелгән датадан соң 5 (биш) календарь көн эчендә Башкаручыга Актны кайтарып бирү һәм счет-фактура алу.

4.2.2. Башкаручының сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон документлар рәвешендә составы һәм эчтәлеге буенча гамәлдәге норматив хокукый актларның таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт экспертизасы үткәрү өчен кирәкле документларны Башкаручыга тапшыру.

Тапшырылган документларның сыйфатлы һәм төгәл булуы өчен Заказчы җаваплы була.

4.2.3. Башкаручының рәсми мөрәҗәгате буенча проект документларында кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләр исәпләмәләрен, шулай ук инженерлык эзләнү материалларын мондый рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көне дәвамында тапшыру.

4.2.4. Әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган тәртиптә проект документларына үзгәрешләр кертү җитешсезлекләрне бетерү.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Әлеге килешү шартлары нигезендә хезмәтләр өчен түләүне таләп итү.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсынучы оешмалардан дәүләт экспертизасын үткәрү һәм Башкаручыга йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен зарури материалларны сорату.

4.3.3. Заказчының ризалыгыннан башка дәүләт экспертизасын үткәрү өчен бүтән дәүләти һәм (яисә) дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итү.

4.3.4. Әлеге килешүнең 4.2.4 пункты нигезендә, Башкаручы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, чикләрдә һәм вакытларда Заказчыга проект документларына үзгәрешләр кертүне тәкъдим итү.

4.3.5. Хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда туктату.

4.4. Башкаручының бурычлары:

4.4.1. Килешүдә һәм норматив хокукый актларда билгеләнгән вакытларда дәүләт экспертизасын үткәрү.

4.4.2. Тапшырылган документларны саклау, шулай ук дәүләт экспертизасы уздыруга бәйле рәвештә Башкаручыга мәгълүм булган проект чишелешләрен өченче затларга белдермәү буенча чаралар күрергә, әлеге документлар һәм мәгълүмат дәүләт мәгълүмат системаларына кертелергә тиешле яки федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органнарга (оешмаларга) җибәрелергә тиешле булган очраклардан тыш.

4.4.3. Килешү рәсмиләштерелгәч, хезмәт күрсәтелгәч Акт нигезендә Заказчыга әлеге килешү шартларында уңай яисә тискәре бәяләмә бирергә.

4.4.4. Россия Федерациясе законнарында каралган чорларда Заказчыга счет-фактура(лар) рәсмиләштерү һәм бирү (җибәрү).

## 5. Килешүне өзү тәртибе

5.1. Заказчы гаризасы буенча әлеге Килешү вакытыннан алда (экспертиза уздырыла торган чорда) өзелергә мөмкин, шул ук вакытта гариза килгән вакытка каралган документларның экспертиза бәясе тотып калына. Килешүне өзүгә бәйле рәвештә Башкаручы тоткан чыгымнарны Заказчы барлык эш өчен билгеләнгән түләү күләме белән башкарылган эшкә түләнгән түләү өлеше арасындагы аерма чикләрендә түләргә бурычлы.

5.2. Заказчы Килешү шартларын бозган очракта, Килешү Башкаручы инициативасы буенча өзелә, шул исәптән:

5.2.1. Заказчы тарафыннан әлеге Килешүдә һәм гамәлдәге законнарда каралган документлар һәм проект документлары тапшырылмаганда;

5.2.2. Заказчының түләү вакытын 30 (утыз) календарь көннән артыграк кичектергәндә;

5.2.3. Заказчы Башкаручыга белә торып төгәл булмаган һәм/яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырганда.

5.2.4. Заказчы экспертиза уздыру барышында проект документларында һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрендә ачыкланган җитешсезлекләрне билгеләнгән срокта бетермәгән очракта:

Дәүләтнеке булмаган экспертизаны уздырганда проект документларында проект документларының техник регламентларның һәм башка норматив документларның таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (мәгълүматларның, тасвирламаларның, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы (тулы булмавы)) ачыкланган очракта, Башкаручы ачыкланган җитешсезлекләр турында Заказчыга кичекмәстән хәбәр итә һәм, кирәк булган очракта, аларны бетерү срогын билгели – кисәтүләр Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсендә теркәлгән көннән башлап 8 календарь көн.

Ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләтнеке булмаган экспертиза барышында билгеләнгән срокта бетерү мөмкин булмаса яки Заказчы аларны билгеләнгән срокта юкка чыгармаса, Башкаручы алга таба экспертиза уздырудан баш тартырга һәм Килешүне вакытыннан алда өзү мәсьәләсен күтәрергә хокуклы, бу хакта, кабул ителгән карар нигезләрен күрсәтеп, Килешүнең 5.2 пунктында билгеләнгән срок узган вакыттан башлап өч көн эчендә Заказчыга язмача хәбәр итә.

5.3. Килешүне өзү турында рәсми рәвештә Башкаручыга яки Заказчыга хәбәр ителгәннән соң, ләкин хәбәр итү вакытыннан башлап 1 (бер) ай узганчы Килешү өзелгән булып санала.

## 6. Махсус шартлар

6.1. Проект документлары һәм (яисә) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре федераль һәм республика законнарындагы таләпләрне бозып үтәлгән очракта, ә аның күләме һәм эчтәлеге проект чишелешен нигезләү өчен җитәрлек булмаганда, Башкаручы алдан кисәтүләр ясамыйча гына тискәре бәяләмә бирү хокукына ия була.

Дәүләт экспертизасы уздырылган вакытта Заказчы Башкаручы күрсәтмәсе буенча һәм ул билгеләгән тәртиптә, чикләрдә һәм срокларда проект документларына оператив рәвештә, ләкин дәүләт экспертизасын уздыру срогы тәмамланырга кимендә 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертә.

Эксперт бәясе нигезендә Башкаручы мөстәкыйль рәвештә үзгәрешләрне оператив рәвештә кертү һәм (яки) җитешсезлекләрне бетерү һәм Заказчыга тиешле күрсәтмәләрне җибәрү мөмкинлеге һәм зарурлыгы турында карар кабул итә.

6.2. Әлеге килешүнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документлар Заказчы тарафыннан тапшырылмаган очракта, килешү әлеге килешүнең 4.2.2, 4.2.3 пунктларында күрсәтелгән документларның Заказчы тарафыннан тапшырылмаган көннәре белән документларны тапшыру датасы арасындагы көннәр исәбеннән артмаган чорга озынайтыла.

6.3. Заказчы белән документлар һәм мәгълүмат алмашу Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

5.4. Бәяләмәне бирү көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада гамәлгә ашырыла.

6.5. Бу килешү карата РФ Граждан кодексының 720 статьясындагы нигезләмәләр кулланылмый.

## 7. Килешүдән барлыкка килә торган бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы, форс-мажор

7.1. Килешү буенча бурычларын үтәмәгән һәм тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

7.2. Әлеге килешү буенча бурычларның үтәлмәве күрелмәгән һәм гадәттән тыш характердагы, булдырмый калу мөмкинлеге калмаган вакыйгалар нәтиҗәсендә җиңеп булмаслык көчле хәлләр нәтиҗәсендә яисә башка якның гаебе белән килеп чыкса, Яклар бурычларны өлешчә яисә тулысынча үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә.

7.3. Төп бурыч суммасын түләү вакыты кичектерелгәндә, РФ Граждан кодексының 317.1 статьясының 1 пункты нигезендә, бу суммага акча чараларыннан файдаланган өчен түләү булып хезмәт итүче процентлар да, РФ Граждан кодексының 395 статьясында билгеләнгән граждан-хокук җаваплылыгы чарасыннан гыйбарәт булган процентлар да өстәлә.

4.4. Килешү буенча ризасызлыклар һәм бәхәсләр Якларның сөйләшүләре, ә ризалыкка ирешелмәгән очракта, Татарстан Республикасы Арбитраж судына мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Бу килешү Заказчы тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылган көннән башлап үз көченә керә һәм Яклар өчен мәҗбүри булып тора һәм Якларның бер-берсе каршындагы бурычлары тулысынча үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

8.2. Әлеге килешүгә кертелә торган үзгәрешләр аңа өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

8.3. Хәзергесе белән Яклар үзләренең, аларның аффилир затларының, хезмәткәрләренең яисә арадашчыларының бу Килешү имзаланган вакытка кадәр, шулай ук әлеге Килешү буенча бурычларны үтәү вакытында нинди дә булса хокукка каршы килә торган өстенлекләрне алу яисә башка төрле хокукка каршы килә торган максатларга ирешү максатында, шул исәптән бу Килешүне имзалату максатларында затларның гамәлләренә яисә карарларына йогынты ясау өчен нинди дә булса акча чараларын түләмәве/түләмәячәге, тәкъдим итмәве/тәкъдим итмәячәкләре һәм түләргә ризалык бирмәве/ризалык бирмәячәкләре, шулай ук ришвәт бирү яисә алу, коммерциячел сатып алу кебек квалификацияләнүче, Россия Федерациясенең җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы көрәш турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында законнары таләпләрен боза торган гамәлләрне гамәлгә ашырмавы турында раслыйлар.

Югарыда аталган теләсә кайсы хәл барлыкка килгән очракта бу нигезләмәләрнең бозылуы хакында белеп алган зат бу хакта Якларның җитәкчелегенә кичекмәстән хәбәр итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

5.4. Документның килешү буенча Як тарафыннан чыгуын төгәл билгеләү мөмкинлеген бирә торган электрон элемтә чаралары ярдәмендә документлар алышу юлы белән язмача формада төзелгән булсалар, әлеге килешү, шулай ук аңа карата теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр гамәлдә була. Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар әлеге килешүдә күрсәтелгән Якларның вәкаләтле вәкилләренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныклана.

Кәгазь чыганакта яки электрон формада төзелә торган килешү Яклар тарафыннан Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яисә кәгазь чыганакта кулдан имзаланырга мөмкин.

8.5. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия булган 2 (ике) нөсхәдә, һәр Якка берәр нөсхәдә төзелде.

5.6. Бу килешүгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора:

– түләү күләме (килешү кушымтасы) 1 биттә.

8.7. Үзләренең адреслары һәм түләү реквизитлары үзгәрүе турында Яклар 10 көнлек чорда язмача бер-берсенә хәбәр итәргә тиеш.

## 9. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары:

| | |
|---|---|
| ЗАКАЗЧЫ:<br>Юридик адрес:<br>Фактик адрес:<br>И-х/с<br><br>Банк тәңгәллек коды<br>Салым түләүченең тәңгәллек номеры<br>КПП | БАШКАРУЧЫ:<br>«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе<br>Юридик адрес: 420073, Казан шәһәре, Шуртыгин ур., 22<br>Почта адресы: 420054, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 125. ИНН 1654017928/КПП 166001001 «Ак Барс» Банк ГАҖ Казан шәһәре<br>Алучы: ТР Финанс министрлыгы (ГАУ «УГЭЦ РТ» |

л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен) р/с
40601810700023000003 БИК 049205805 К/с
30101810000000000805

Килешүгә кушымта
___________ ____________

Торак булмаган капиталь төзелеш объектларының проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү бәясен исәпләү

Объект:
Заказчы:
Агымдагы бәяләрдә экспертиза үткәрү хакы: $C_{ЭТЕК} = (C_{пр} \times K_i + C_{из} \times K_i) \times П \times НДС$

$C_{ЭТЕК} = руб.$, биредә

$C_{пр} =$ - 2001 ел бәяләрендә проект документларын әзерләү хакы.

$C_{из} =$ - 2001 ел бәяләрендә эзләнү эшләренең хакы.

$K_i =$ - 01.01.01 белән чагыштырмача 01.01.15 карата инфляция индексы.

П = - РФ Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары кушымтасы буенча 2001 елгы бәяләр дәрәҗәсендә дәүләт экспертизасына тапшырылган проект һәм (яисә) тикшеренү эшләренең суммар хакыннан өлеш.

Моннан тыш, өстәлгән кыйммәт салымы - 20% - сум.

Башкарылган эшләрнең хакы – сум.

Исәпләмәне башкарды ________________

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 1.1 нче кушымта

Киңәш итеlә торган форма

Түләүле хезмәт күрсәтү буенча № килешү

Казан ш.

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя куюю идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе (Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе), алга таба «Башкаручы» дип исемләнеп, ____________________________ нигезендә гамәл кылучы _______________ йөзендә, бер яктан, һәм _______________________ нигезендә гамәл кылучы ________________________ йөзендә, алга таба «Заказчы» дип исемләнеп, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип исемләнеп, әлеге килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

## 1. Килешүнең предметы

Проект документларына эксперт тарафыннан бәяләү үткәрүгә граждани-хокукый әлеге килешү (алга таба – килешү) шартлары буенча Башкаручы Заказчы гаризасы буенча «________________________» дәүләт экспертизасын үткәрү (алга таба – хезмәтләр күрсәтү, дәүләт экспертизасы) бурычын, ә Заказчы бу хезмәт күрсәтү өчен түләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләрен кабул итеп алу бурычын үз өстенә ала.

Проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәсе булып проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитар-эпидемиологик таләпләргә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсе таләпләренә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз файдалану таләпләренә, сәнәгый куркынычсызлык таләпләренә, электр энергиясе системаларының һәм электр энергиясе объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата таләпләргә, объектның террорчылыкка каршы яклану таләпләренә, төзүченең яки техник заказчының проектлау биремена, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлешенә ярашлы булуын да кертеп, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүен (уңай) яки туры килмәвен (тискәре) раслау турындагы нәтиҗәләрне үз эченә алган бәяләмә тора.

Нигезләмәнең 17.4 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән гариза бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең

проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлеше белән ярашуын, проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитария-эпидемиология таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы яклангану таләпләренә, проектлауга төзүче яисә техник заказчы биременә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелә.

Нигезләмәнең 17.4 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән гариза бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча, проект документларына уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе алынганнан соң проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең проект документларының әлеге үзгәрешләр кертелмәгән өлеше белән ярашуын, шулай ук төзүнең, үзгәртеп коруның смета бәясен дөрес билгеләү яки дөрес билгеләмәү турында да, проект документларына кертелгән үзгәрешләрнең техник регламентлар таләпләренә, санитария-эпидемиология таләпләренә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә, мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау таләпләренә, атом энергиясен куркынычсыз куллану таләпләренә, сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләренә, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә, объектның террорчылыкка каршы яклангану таләпләренә, проектлауга төзүче яисә техник заказчы биременә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында дәүләт экспертизасы бәяләмәсе бирелә.

Югарыда аталган капиталь төзелеш объекты буенча проект документларына карата элегрәк дәүләт экспертизасы уздырылды, аның нәтиҗәләре буенча уңай бәяләмә бирелде ________________________________________________________________________________
__________________.

(дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең датасы һәм номеры)

## 2. Дәүләт экспертизасы үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә түләү һәм исәп-хисап ясау тәртибе

2.1. Экспертиза бәясе Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

2.2. Бу килешүнең 1.1 пункты нигезендә Заказчы дәүләт экспертизасы үткәрү бәясен Башкаручыга түләү күләменә (әлеге килешүнең 1 нче кушымтасы) туры китереп түли, аның күләме – ____________________ тәшкил итә, шул исәптән 20%лы ставка буенча өстәмә хак салымы – ________________________.

Дәүләт экспертизасы үткәрү барышында проект документларының, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең күләме арткан очракта һәм (яисә) карала торган проект документлары буенча проект-эзләнү эшләренең бәясе үзгәртелгәндә, килешү буенча экспертизаның бәясе тәгаенләштерелергә тиеш.

2.3. Хезмәткә түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе нинди булуга бәйсез рәвештә түләнә.

2.4. Заказчы әлеге килешү имзаланган вакыттан башлап 5 эш көне эчендә хезмәтләр бәясенең 100% күләмендә аванс түләү бурычын үз өстенә ала. Башкаручы аванс суммасы килгән көннән башлап исәпләнә торган 5 календарь көннән соңга калмыйча, Заказчыга күрсәтеләчәк хезмәтләр өчен счетка аванс түләве буенча счет-фактура бирә.

2.5. Счетны түләү көне булып акча чараларының Башкаручының исәп-хисап счетына килгән, банк өземтәсендә расланган көн санала.

2.6. Эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүне озайтканда, түләү күләме беренчел дәүләт экспертизасын үткәрү өчен эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешү озайтыла торган датага исәпләнгән түләү күләменең 30 процентын тәшкил итә.

2.7. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе нигезендә акча чараларын өченче зат тарафыннан Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты

3.1. Эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү 1 елга төзелә.

Эксперт тарафыннан бәяләү срогы, эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүнең вакыты беткәнчегә кадәр кимендә 30 эш көне алдан Заказчы Башкаручыга эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешүе вакытын арттыру турында хәбәр итсә, озайтылырга тиеш.

3.2. Эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе Нигезләмәнең 17.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган көнне әзерләнә башлый һәм капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыру белән тәмамлана.

3.3. Эксперт тарафыннан бәяләү эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү төзелгәннән соң һәм эксперт тарафыннан бәяләү турындагы килешү нигезендә түләү кертелгәнлеген раслый торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылганнан соң башлана.

3.4. Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү эше мөрәҗәгать итүче Нигезләмәнең 17.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң башлана һәм эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллекне бәяләү нәтиҗәләре буенча бәяләмне мөрәҗәгать итүчегә тапшыру белән төгәлләнә.

3.5. Эксперт тарафыннан бәяләү кысаларында тәңгәллеккә бәя бирүне үткәрү вакыты Нигезләмәнең 17.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң иң күбе 10 эш көне. Әлеге срок Башкаручы тарафыннан ярашлылык бәясенә тәкъдим ителә торган проект документларына үзгәрешләр проект документларының 2 һәм аннан да күбрәк бүлегенә кертелгән очракта арттырыла ала, ләкин иң күбе 10 эш көненә кадәр генә.

3.6. Эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсен тапшыру чоры Нигезләмәнең 17.4 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән гаризаны Башкаручыга тапшырган көннән башлап 15 эш көненнән һәм Нигезләмәнең 17.4 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән документларны Башкаручыга тапшырган көннән башлап 35 эш көненнән артык була алмый.

3.7. Дәүләт экспертизасы уздыру буенча хезмәт күрсәтү Яклар тарафыннан имзаланган дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне тапшыру-кабул итү акты белән раслана (алга таба – «Акт»).

3.8. Әгәр Заказчы Актка кул куюдан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән көннән соңгы 5 (биш) календарь көн эчендә язмача баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән вакытларда дәлилле баш тарту тапшырылмаса, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә нинди дә булса ризасызлыкларсыз күрсәтелгән дип санала. Дәлилле баш тартуда әлеге килешүдә каралган бурычлар чиген уздырмый торган кисәтүләр булырга тиеш.

## 4. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Дәүләт экспертизасын үткәрү барышы турында мәгълүмат алу һәм Башкаручыга зарури аңлатмаларны, өстәмә белешмәләрне һәм документларны тапшыру.

4.1.2. Заказчының Башкаручы сайтындагы шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, өстәмә документларны электрон документ формасында Башкаручыга тапшыру.

Оператив рәвештә Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документларына үзгәрешләр кертү.

4.1.3. Нигезләмәнең 17.4 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән очракта, эксперт тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча дәүләт экспертизасы бәяләмәсе әзерләнгәндә, төзелеш, үзгәртеп кору сметасына оператив рәвештә, ләкин дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты тәмамланганчы кадәр кимендә 10 эш көне алдан үзгәрешләр кертүне гамәлгә ашырырга.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән килешүне имзалау һәм Башкаручыга кайтару, әлеге килешү нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен түләү.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, Акт буенча күрсәтелгән хезмәтне кабул итү, имзалау һәм уңай яисә тискәре бәяләмә рәсмиләштерелгән датадан соң 5 (биш) календарь көн эчендә Башкаручыга Актны кайтарып бирү һәм счет-фактура алу.

4.2.2. Башкаручының сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон документлар рәвешендә составы һәм эчтәлеге буенча гамәлдәге норматив хокукый актларның таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт экспертизасы үткәрү өчен кирәкле документларны Башкаручыга тапшыру.

Тапшырылган документларның сыйфатлы һәм төгәл булуы өчен Заказчы җаваплы була.

4.2.3. Башкаручының рәсми мөрәҗәгате буенча проект документларында кулланыла торган конструктив һәм технологик чишелешләрнең исәпләмәләрен, шулай ук инженерлык эзләнү материалларын мондый рәсми мөрәҗәгать алынган вакыттан соң 5 көн дәвамында тапшыру.

4.2.4. Проект документларына үзгәрешләр кертү һәм җитешсезлекләрне бетерү.

4.2.5. Килешүнең гамәлдә булу чоры бетәргә кимендә 30 эш көне калгач Нигезләмәнең 17.4 пунктындагы «а» яки «б» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаны яисә эксперт тарафыннан бәяләү турында килешүнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны җибәрергә.

Күрсәтелгән гаризалар булмаган очракта, хезмәт тулы күләмдә күрсәтелгән дип санала.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Әлеге килешү шартлары нигезендә хезмәтләр өчен түләүне таләп итү.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсынучы оешмалардан дәүләт экспертизасын үткәрү һәм Башкаручыга йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен зарури материалларны сорату.

4.3.3. Заказчының ризалыгыннан башка дәүләт экспертизасын үткәрү өчен бүтән дәүләти һәм (яисә) дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итү.

4.3.4. Заказчыга әлеге килешүнең 4.2.4 пунктында каралган тәртиптә проект документларына үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

4.4. Башкаручының бурычлары:

4.4.1. Килешүдә һәм норматив хокукый актларда билгеләнгән вакытларда дәүләт экспертизасын үткәрү.

4.4.2. Тапшырылган документларны саклау, шулай ук дәүләт экспертизасы уздыруга бәйле рәвештә Башкаручыга мәгълүм булган проект чишелешләрен өченче затларга белдермәү буенча чаралар күрергә, әлеге документлар һәм мәгълүмат дәүләт мәгълүмат системаларына кертелергә тиешле яки федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органнарга (оешмаларга) җибәрелергә тиешле булган очраклардан тыш.

4.4.3. Килешү рәсмиләштерелгәч, хезмәт күрсәтелгәч Акт нигезендә Заказчыга әлеге килешү шартларында уңай яисә тискәре бәяләмә бирергә.

4.4.4. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган чорларда Заказчыга счет-фактура(лар) рәсмиләштерү һәм бирү (җибәрү).

## 5. Килешүне өзү тәртибе

5.1. Әлеге килешү Заказчының гаризасы нигезендә вакытыннан алда (хезмәт күрсәтелгән чорда) таркатылырга мөмкин, шул ук вакытта гариза кергән вакытка күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе тотып калына. Әлеге килешүне туктатуга бәйле рәвештә Башкаручыга китерелгән югалтуларны Заказчы барча эш өчен билгеләнгән түләү күләме белән башкарылган эшкә түләнгән түләү өлеше арасындагы аерма чикләрендә түләргә бурычлы.

5.2. Башкаручы бер яклы тәртиптә әлеге Килешүне үтәүдән судка мөрәҗәгать итмичә баш тартырга хокуклы, түбәндәге очракларда:

5.2.1. 4.2.2 пукнт нигезендә Заказчы тарафыннан документларны тапшыру вакытын уздырып җибәргән очракта;

5.2.2. Заказчы Башкаручыга белә торып төгәл булмаган һәм/яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшырганда.

5.3. Әлеге Килешүнең 5.2 пунктында күрсәтелгән шартлар барлыкка килгәндә, Башкаручы килешүне өзүнең планлаштырылган датасына кадәр 10 эш көненнән соңга калмыйча Заказчыга таркату датасын күрсәтеп, бу килешүне үтәүдән баш тарту (килешүне өзү) турында тиешле язмача хәбәр җибәрә. Хәбәрдә күрсәтелгән датадан башлап Килешү өзелгән булып санала.

5.4. Әлеге килешүнең 5.2 пункты нигезендә әлеге килешү өзелгән очракта, Заказчы хезмәтләрнең тулы бәясен түләргә бурычлы.

## 6. Махсус шартлар

6.1. Заказчы белән документлар һәм мәгълүмат алмашу Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

6.2. Бәяләмәне бирү көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада гамәлгә ашырыла.

6.3. Әлеге килешүгә карата Россия Федерациясе Граждан кодексының 720 статьясы (алга таба – РФ ГК) нигезләмәләре кулланылмый.

## 7. Килешү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы, форс-мажор

7.1. Килешү буенча бурычларын үтәмәгән һәм тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы була.

7.2. Әлеге килешү буенча бурычларның үтәлмәве күрелмәгән һәм гадәттән тыш характердагы, булдырмый калу мөмкинлеге калмаган вакыйгалар нәтиҗәсендә җиңеп булмаслык көчле хәлләр нәтиҗәсендә яисә башка якның гаебе белән килеп чыкса, Яклар бурычларны өлешчә яисә тулысынча үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә.

7.3. Төп бурыч суммасын түләү вакыты кичектерелгәндә, РФ ГК 317.1 статьясының 1 пункты нигезендә, бу суммага акча чараларыннан файдаланган өчен түләү булып хезмәт итүче процентлар да, РФ ГК 395 статьясында билгеләнгән гражданый-хокукый җаваплылыгы чарасыннан гыйбарәт булган процентлар да өстәлә.

7.4. Килешү буенча ризасызлыклар һәм бәхәсләр Якларның сөйләшүләре, ә ризалыкка ирешелмәгән очракта Татарстан Республикасы Арбитраж судына мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

## 8. Ахыргы нигезләмәләр

8.1. Бу килешү Заказчы тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылган, хезмәткә түләнгән вакыттан башлап үз көченә керә һәм Яклар өчен мәҗбүри була һәм Якларның каракаршы бурычлары тулысынча үтәлгәнчегә кадәр гамәлдә була.

8.2. Әлеге килешүгә кертелә торган үзгәрешләр аңа өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

8.3. Килешүнең гамәлдә булу чоры бетәргә кимендә 30 эш көне калгач Заказчы Нигезләмәнең 17.4 пунктындагы «а» яки «б» пунктчаларында күрсәтелгән гаризаны яисә эксперт тарафыннан бәяләү турында килешүнең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны җибәрмәсә, хезмәт тулы күләмендә күрсәтелгән дип санала.
Аванс сыйфатында түләнгән акчалар кире кайтарылырга тиеш түгел.

8.4. Хәзергесе белән Яклар үзләренең, аларның аффилир затларының, хезмәткәрләренең яисә арадашчыларының бу Килешү имзаланган вакытка кадәр, шулай ук әлеге Килешү буенча бурычларны үтәү вакытында нинди дә булса хокукка каршы килә торган өстенлекләрне алу яисә башка төрле хокукка каршы килә торган максатларга ирешү максатында, шул исәптән бу Килешүне имзалату максатларында затларның гамәлләренә яисә карарларына йогынты ясау өчен нинди дә булса акча чараларын түләмәве/түләмәячәге, тәкъдим итмәве/тәкъдим итмәячәкләре һәм түләргә ризалык бирмәве/ризалык бирмәячәкләре, шулай ук ришвәт бирү яисә алу, коммерциячел сатып алу кебек квалификацияләнүче, Россия Федерациясенең җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы көрәш турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында законнары таләпләрен боза торган гамәлләрне гамәлгә ашырмавы турында раслыйлар.

Югарыда аталган теләсә кайсы хәл барлыкка килгән очракта бу нигезләмәләрнең бозылуы хакында белеп алган зат бу хакта Якларның җитәкчелегенә кичекмәстән хәбәр итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

8.5. Документның килешү буенча Як тарафыннан чыгуын төгәл билгеләү мөмкинлеген бирә торган электрон элемтә чаралары ярдәмендә документлар алышу юлы белән язмача формада төзелгән булсалар, әлеге килешү, шулай ук аңа карата теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр гамәлдә була. Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар әлеге килешүдә күрсәтелгән Якларның вәкаләтле вәкилләренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныклана.

Кәгазь чыганакта яки электрон формада төзелә торган килешү Яклар тарафыннан Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яисә кәгазь чыганакта кулдан имзаланырга мөмкин.

8.6. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия булган 2 (ике) нөсхәдә, һәр Якка берәр нөсхәдә төзелде.

8.7. Бу килешүгә түбәндәгеләр теркәлә һәм аның аерылгысыз өлеше булып тора:
– түләү күләме (әлеге килешүнең 1 нче кушымтасы) 1 биттә.

8.8. Үзләренең адреслары һәм түләү реквизитлары үзгәрүе турында Яклар 10 көнлек чорда язмача бер-берсенә хәбәр итәргә тиеш.

## 9. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары:

ЗАКАЗЧЫ:

БАШКАРУЧЫ:
«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе
Юридик адрес:
420073, Казан ш., Шуртыгин ур.,

22

Почта адресы: 420054, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 125.

ИНН 1654017928/ КПП 166001001

Казан ш. «Ак Барс» ХАҖ

Алучысы: ТР Финанс министрлыгы

(ГАУ «УГЭЦ РТ» л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)

р/с 40601810700023000003

БИК 049205805

К/с 30101810000000000805

Килешүгә 1 нче кушымта
№ ______________________________

Эксперт тарафыннан бәяләү өчен түләү күләме

Карау объекты: ____________________________________________________

Заказчы : ___________________________________________________________

Хәзерге бәяләрдә экспертиза уздыру бәясе: РПнж = Спд х П х Кі + Сиж х П х Кі хНДС

РПнж = (___________× ____ + _________ × ________) × ____ = ________ сум,

биредә:

Спд - Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән сметалы нормалаштыру һәм бәя кую өлкәсендәге документлар нигезендә 2001 ел бәяләрендә исәпләнгән дәүләт экспертизасына тәкъдим ителгән проект документларын әзерләү бәясе (сумнарда);

Сиж - Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән сметалы нормалаштыру һәм бәя кую өлкәсендәге документлар нигезендә 2001 ел бәяләрендә исәпләнгән дәүләт экспертизасына тәкъдим ителгән инженерлык эзләнү материалларын әзерләү бәясе (сумнарда);

Кі 5,44 - 2001 елның 1 гыйнварыннан башлап чагыштырганда инфляция күренешләрен чагылдыра торган коэффициент, ул 2000 елдан соңгы һәр ел өчен дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү күләме билгеләнә торган елдан алда килгән елга кадәр Дәүләт статистикасы федераль хезмәте тарафыннан бастырып чыгарыла торган кулланучылар бәяләре индексларының тапкырчыгышы буларак билгеләнә

И - кушымта нигезендә дәүләт экспертизасына тапшырылган проект һәм (яки) эзләнү эшләренең суммар бәя проценты

0,3 (30%) – эксперт белән эш иткән өчен эксперт тарафыннан бәяләү турында килешү төзү датасына исәпләнгән беренчел дәүләт экспертизасын үткәргән өчен түләү күләменең 30 проценты күләмендә түләү алына.

Эксперт белән эш иткән өчен түләү күләме: ____________ сум. х 0,3 (30%) х 1,2 (20% ӨХС)=___________ сум.

Шул исәптән 20% ӨХС - ____________ сум

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
2 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Түләүле хезмәтләр күрсәтү килешүе

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе (Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе), алга таба «Башкаручы» дип исемләнеп, ___________________________ нигезендә гамәл кылучы _______________ йөзендә, бер яктан, һәм ______________________ нигезендә гамәл кылучы _______________________ йөзендә, алга таба «Заказчы» дип исемләнеп, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип исемләнеп, әлеге килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

1. Килешүнең предметы

1.1. Проект документларына күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонтның смета бәясен билгеләүнең тәгәллеген тикшерү өлешендә дәүләт экспертизасы үткәрүгә әлеге килешү (алга таба – килешү) шартлары буенча Башкаручы Заказчы гаризасы буенча «________________________» дәүләт экспертизасын үткәрү (алга таба – хезмәтләр күрсәтү, дәүләт экспертизасы) бурычын, ә Заказчы бу хезмәт күрсәтү өчен түләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләрен кабул итеп алу бурычын үз өстенә ала.

1.2. Проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла

1.3. Дәүләт экспертизасы нәтиҗәсе булып смета бәясен билгеләүнең тәгәллеге (уңай бәяләмә) яки тәгәл булмавы (тискәре бәяләмә) турында бәяләмә тора.

2. Дәүләт экспертизасын үткәрү буенча хезмәтләргә түләү һәм исәп-хисап ясау тәртибе

2.1. Нигезләмә нигезендә, экспертиза бәясе 24 000 сум 00 тиен тәшкил итә, шул исәптән 20% ставка буенча өстәмә хак салымы (ӨХС) – 4 000 сум 00 тиен;

2.2. Хезмәткә түләү дәүләт экспертизасының нәтиҗәсе нинди булуга бәйсез рәвештә түләнә.

2.3. Счетны түләү көне булып акча чараларының Башкаручының исәп-хисап счетына килгән, банк өземтәсендә расланган көн санала.

2.4. Түләү Заказчының язмача күрсәтмәсе нигезендә акча чараларын өченче зат тарафыннан Башкаручының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән башкарылырга мөмкин.

## 3. Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты

3.1. Капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонтның смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы 21 эш көне дәвамында үткәрелә.

Дәүләт экспертизасын үткәрү вакыты заказчының язмача мөрәҗәгате нигезендә 20 эш көненә озайтылырга мөмкин.

Башкаручы хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда тәмамларга һәм Заказчыга эш нәтиҗәсен – бәяләмә бирергә хокуклы.

3.2. Төзелешен, үзгәртеп корылышын яки капиталь ремонтын финанслау Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетлар акчасын, дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата проект документларына дәүләт экспертизасы килешү төзелгәннән соң уздырыла башлый һәм Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгәч (тапшырылгач) тәмамлана.

Башка капиталь төзелеш объектларына карата проект документларына дәүләт экспертизасы мөрәҗәгать итүче килешү нигезендә дәүләт экспертизасы уздырган өчен түләү кертелүен раслый торган документларны тапшырганнан соң уздырыла башлый һәм мөрәҗәгать итүчегә Капиталь төзелеш объектлары проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсе тапшырылганнан (җибәрелгәннән) соң тәмамлана.

3.3. Дәүләт экспертизасы уздыру буенча хезмәт күрсәтү Яклар тарафыннан имзаланган дәүләт экспертизасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне тапшыру-кабул итү акты белән раслана (алга таба – «Акт»).

3.4. Әгәр Заказчы Актка кул куюдан баш тартса, ул вакытта ул Башкаручыга Актны алган һәм Башкаручы тарафыннан хезмәт күрсәтелгән көннән соңгы 5 (биш) календарь көн эчендә язмача баш тартуны тапшырырга бурычлы. Әгәр дә Заказчы тарафыннан Башкаручыга билгеләнгән вакытларда дәлилле баш тарту тапшырылмаса, Акт Заказчы тарафыннан имзаланган һәм хезмәт Башкаручы тарафыннан тулы күләмендә нинди дә булса ризасызлыкларсыз күрсәтелгән дип санала. Дәлилле баш тартуда әлеге килешүдә каралган бурычлар чиген уздырмый торган кисәтүләр булырга тиеш.

## 4. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Заказчының хокуклары:

4.1.1. Дәүләт экспертизасын үткәрү барышы турында мәгълүмат алу һәм Башкаручыга зарури аңлатмаларны, өстәмә белешмәләрне һәм документларны тапшыру.

4.1.2. Заказчының Башкаручы сайтындагы шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, өстәмә документларны электрон документ формасында Башкаручыга тапшыру.

Оператив рәвештә Башкаручы тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен проект документларына үзгәрешләр кертү.

4.2. Заказчының бурычлары:

4.2.1. Рәсмиләштерелгән килешүне имзалау һәм Башкаручыга кайтару, әлеге килешү нигезендә хезмәтләр күрсәтү өчен түләү.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә бәйсез рәвештә, Акт буенча күрсәтелгән хезмәтне кабул итү, имзалау һәм уңай яисә тискәре бәяләмә рәсмиләштерелгән датадан соң 5 (биш) календарь көн эчендә Башкаручыга Актны кайтарып бирү һәм счет-фактура алу.

4.2.2. Башкаручының сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон документлар рәвешендә составы һәм эчтәлеге буенча гамәлдәге норматив хокукый актларның таләпләренә җавап бирә торган, дәүләт экспертизасы үткәрү өчен кирәкле документларны Башкаручыга тапшыру.

Тапшырылган документларның сыйфатлы һәм төгәл булуы өчен Заказчы җаваплы була.

4.2.3. Әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган тәртиптә проект документларына үзгәрешләр кертү җитешсезлекләрне бетерү.

4.3. Башкаручының хокуклары:

4.3.1. Әлеге килешү шартлары нигезендә хезмәтләр өчен түләүне таләп итү.

4.3.2. Дәүләт хакимияте органнарыннан, аларга буйсынучы оешмалардан дәүләт экспертизасын үткәрү һәм Башкаручыга йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен зарури материалларны сорату.

4.3.3. Заказчының ризалыгыннан башка дәүләт экспертизасын үткәрү өчен бүтән дәүләти һәм (яисә) дәүләтнеке булмаган оешмаларны, шулай ук белгечләрне җәлеп итү.

4.3.4. Заказчыга Башкаручы билгеләгән тәртиптә, чикләрдә һәм срокларда проект документларына үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

4.3.5. Хезмәт күрсәтүне вакытыннан алда туктату.

4.4. Башкаручының бурычлары:

4.4.1. Килешүдә һәм норматив хокукый актларда билгеләнгән вакытларда дәүләт экспертизасын үткәрү.

4.4.2. Тапшырылган документларны саклау, шулай ук дәүләт экспертизасы уздыруга бәйле рәвештә Башкаручыга мәгълүм булган проект чишелешләрен өченче затларга белдермәү буенча чаралар күрергә, әлеге документлар һәм мәгълүмат дәүләт мәгълүмат системаларына кертелергә тиешле яки федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органнарга (оешмаларга) җибәрелергә тиешле булган очраклардан тыш.

4.4.3. Килешү рәсмиләштерелгәч, хезмәт күрсәтелгәч Акт нигезендә Заказчыга әлеге килешү шартларында уңай яисә тискәре бәяләмә бирергә.

4.4.4. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган чорларда Заказчыга счет-фактура(лар) рәсмиләштерү һәм бирү (җибәрү).

## 5. Килешүне өзү тәртибе

5.1. Заказчы гаризасы буенча әлеге Килешү вакытыннан алда (экспертиза уздырыла торган чорда) өзелергә мөмкин, шул ук вакытта гариза килгән вакытка каралган документларның экспертиза бәясе тотып калына. Килешүне өзүгә бәйле рәвештә Башкаручы тоткан чыгымнарны Заказчы барлык эш өчен билгеләнгән түләү күләме белән башкарылган эшкә түләнгән түләү өлеше арасындагы аерма чикләрендә түләргә бурычлы.

5.2. Заказчы Килешү шартларын бозган очракта, Килешү Башкаручы инициативасы буенча өзелә, шул исәптән:

5.2.1. Заказчы тарафыннан әлеге Килешүдә һәм гамәлдәге законнарда каралган документлар һәм проект документлары тапшырылмаганда;

5.2.2. Заказчының түләү вакытын 30 (утыз) календарь көннән артыграк кичектергәндә;

5.2.3. Заказчы Башкаручыга белә торып төгәл булмаган һәм/яки тулы булмаган

мәгълүматлар тапшырганда.

5.2.4. Заказчы экспертиза уздыру барышында проект документларында ачыкланган җитешсезлекләрне билгеләнгән срокта бетермәгән очракта:

Дәүләтнеке булмаган экспертизаны уздырганда проект документларында проект документларының техник регламентларның һәм башка норматив документларның таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми торган җитешсезлекләр (мәгълүматларның, тасвирламаларның, сызымнарның, схемаларның һ.б. булмавы (тулы булмавы)) ачыкланган очракта, Башкаручы ачыкланган җитешсезлекләр турында Заказчыга кичекмәстән хәбәр итә һәм, кирәк булган очракта, аларны бетерү срогын билгели – кисәтүләр Дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсендә теркәлгән көннән башлап 8 календарь көн.

Ачыкланган җитешсезлекләрне дәүләтнеке булмаган экспертиза барышында билгеләнгән срокта бетерү мөмкин булмаса яки Заказчы аларны билгеләнгән срокта юкка чыгармаса, Башкаручы алга таба экспертиза уздырудан баш тартырга һәм Килешүне вакытыннан алда өзү мәсьәләсен күтәрергә хокуклы, бу хакта, кабул ителгән карар нигезләрен күрсәтеп, Килешүнең 5.2 пунктында билгеләнгән срок узган вакыттан башлап өч көн эчендә Заказчыга язмача хәбәр итә.

5.3. Килешүне өзү турында рәсми рәвештә Башкаручыга яки Заказчыга хәбәр ителгәннән соң, ләкин хәбәр итү вакытыннан башлап 1 (бер) ай узганчы Килешү өзелгән булып санала.

## 6. Махсус шартлар

6.1. Проект документлары федераль һәм республика законнарындагы таләпләрне бозып үтәлгән очракта, ә аның күләме һәм эчтәлеге проект чишелешен нигезләү өчен җитәрлек булмаса, Башкаручы алдан кисәтүләр ясамыйча гына тискәре бәяләмә бирү хокукына ия була.

Дәүләт экспертизасы уздырылган вакытта Заказчы Башкаручы күрсәтмәсе буенча һәм ул билгеләгән тәртиптә, чикләрдә һәм срокларда проект документларына оператив рәвештә, ләкин дәүләт экспертизасын уздыру срогы тәмамланырга кимендә 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертә.

Эксперт бәясе нигезендә Башкаручы мөстәкыйль рәвештә үзгәрешләрне оператив рәвештә кертү һәм (яки) җитешсезлекләрне бетерү һәм Заказчыга тиешле күрсәтмәләрне җибәрү мөмкинлеге һәм зарурлыгы турында карар кабул итә.

6.2. Әлеге килешүнең 4.2.2 пунктында күрсәтелгән документлар Заказчы тарафыннан тапшырылмаган очракта килешү бу килешүнең 4.2.2 пунктында күрсәтелгән документларның Заказчы тарафыннан тапшырылмаган көннәре белән документларны тапшыру датасы арасындагы көннәр исәбеннән артмаган чорга озынайтыла.

6.3. Заказчы белән документлар һәм мәгълүмат алмашу Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетыннан файдаланып яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

5.4. Бәяләмәне бирү көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада гамәлгә ашырыла.

6.5. Бу килешү карата РФ Граждан кодексының 720 статьясындагы нигезләмәләр кулланылмый.

## 7. Килешүдән барлыкка килә торган бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы, форс-мажор

7.1. Килешү буенча бурычларын үтәмәгән һәм тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия

Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы була.

7.2. Әлеге килешү буенча бурычларның үтәлмәве күрелмәгән һәм гадәттән тыш характердагы, булдырмый калу мөмкинлеге калмаган вакыйгалар нәтиҗәсендә җиңеп булмаслык көчле хәлләр нәтиҗәсендә яисә башка якның гаебе белән килеп чыкса, Яклар бурычларны өлешчә яисә тулысынча үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә.

7.3. Төп бурыч суммасын түләү вакыты кичектерелгәндә, РФ Граждан кодексының 317.1 статьясының 1 пункты нигезендә, бу суммага акча чараларыннан файдаланган өчен түләү булып хезмәт итүче процентлар да, РФ Граждан кодексының 395 статьясында билгеләнгән гражданлык-хокук җаваплылыгы чарасыннан гыйбарәт булган процентлар да өстәлә.

4.4. Килешү буенча ризасызлыклар һәм бәхәсләр Якларның сөйләшүләре, ә ризалыкка ирешелмәгән очракта, Татарстан Республикасы Арбитраж судына мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

8.1. Әлеге килешү имзаланган көненнән башлап үз көченә керә һәм Яклар бер-берсе каршындагы йөкләмәләрне тулысынча үтәп бетергәнчегә кадәр Яклар өчен гамәлдә була.

8.2. Әлеге килешүгә кертелә торган үзгәрешләр аңа өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

8.3. Хәзергесе белән Яклар үзләренең, аларның аффилир затларының, хезмәткәрләренең яисә арадашчыларының бу килешү имзаланган вакытка кадәр, шулай ук әлеге килешү буенча бурычларны үтәү вакытында нинди дә булса хокукка каршы килә торган өстенлекләрне алу яисә башка төрле хокукка каршы килә торган максатларга ирешү максатында, шул исәптән бу килешүне имзалату максатларында затларның гамәлләренә яисә карарларына йогынты ясау өчен нинди дә булса акча чараларын түләмәве/түләмәячәге, тәкъдим итмәве/тәкъдим итмәячәкләре һәм түләргә ризалык бирмәве/ризалык бирмәячәкләре, шулай ук ришвәт бирү яисә алу, коммерциячел сатып алу кебек квалификацияләнүче, Россия Федерациясенең җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы көрәш турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында законнары таләпләрен боза торган гамәлләрне гамәлгә ашырмавы турында раслыйлар.

Югарыда аталган теләсә кайсы хәл барлыкка килгән очракта бу нигезләмәләрнең бозылуы хакында белеп алган зат бу хакта Якларның җитәкчелегенә кичекмәстән хәбәр итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

5.4. Документның килешү буенча Як тарафыннан чыгуын төгәл билгеләү мөмкинлеген бирә торган электрон элемтә чаралары ярдәмендә документлар алышу юлы белән язмача формада төзелгән булсалар, әлеге килешү, шулай ук аңа карата теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр гамәлдә була. Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар әлеге килешүдә күрсәтелгән Якларның вәкаләтле вәкилләренең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныклана.

Кәгазь чыганакта яки электрон формада төзелә торган килешү Яклар тарафыннан Башкаручының рәсми сайтында Заказчының шәхси кабинетында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яисә кәгазь чыганакта кулдан имзаланырга мөмкин.

8.5. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия булган 2 (ике) нөсхәдә, һәр Якка берәр нөсхәдә төзелде.

5.6. Үзләренең адреслары һәм түләү реквизитлары үзгәрүе турында Яклар 10 көнлек чорда язмача бер-берсенә хәбәр итәргә тиеш.

9. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары:

ЗАКАЗЧЫ:

______________________

______________________

БАШКАРУЧЫ:
«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе
Юридик адрес: 420073, Казан шәһәре, Шуртыгин ур., 22
Почта адресы: 420054, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 125.
ИНН 1654017928/КПП 166001001
«Ак Барс» банк ГАҖ Казан шәһәре
Алучысы: ТР Финанс министрлыгы
(ГАУ «УГЭЦ РТ» л/с ЛАВ00713002-УЭкспЦен)
р/с 40601810700023000003
Банк тәңгәллек коды 049205805
К/с 30101810000000000805

______________________________

______________________________

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
3 нче кушымта

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү өчен тапшырыла торган документлар исемлеге

I. Бер үк вакытта проект документларына һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түбәндәге документлар тапшырыла:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә (шул исәптән документлардагы бүлекләрнең составына һәм эчтәлегенә карата да) капиталь төзелеш объектына проект документлары;

3. смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эш күләмнәре исемлекләре;

4. проектлауга бирем;

5. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән күрсәтелгән нәтиҗәләр составына карата да) нигезендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

6. инженерлык эзләнүләрен үтәү биреме;

7. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

8. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экологик экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү очрагында дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

9. дәүләт катнаша торган зур инвестиция проектына гавами технологик аудит уздырылуы турында уңай җыелма бәяләмә (Россия Федерациясе законнары нигезендә гавами технологик һәм бәя аудитын уздыру мәҗбүри булып торса) яки үзенә карата капиталь төзелеш объектын проектлау, төзү һәм файдалануга кертү эшләрен бер үк вакытта башкару предметыннан гыйбарәт контрактны төзү планлаштырылган капиталь төзелеш объектын оештыру буенча инвестиция проектына гамәлгә ашырыла торган инвестицияләрне нигезләү һәм, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә мондый нигезләүне әзерләү һәм аңа технологик һәм бәя аудиты уздыру мәҗбүри булган очракта, инвестицияләрне нигезләүгә технологик һәм бәя аудиты бәяләмәсе;

10. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше

кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

11. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

12. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла);

13. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;»;

14. хосусый смета нормативларын эшләү һәм куллану турында Россия

Федерациясе Хөкүмәте карары турында белешмәләр (әгәр мондый карар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары белән расланган Проект документлары бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турындагы нигезләмәнең 30 пункты нигезендә кабул ителгән булса);

15. Россия Федерациясенең дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына карата – Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый акты яисә федераль бюджет акчасын төп бүлүченең бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында, капиталь төзелеш объектына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль максатчан программа раслау турында норматив хокукый акты;

16. дәүләт яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт компанияләрен һәм корпорацияләрен дә кертеп, булып тормаган юридик затларның төзелеше, үзгәртеп корылышы Татарстан Республикасы бюджетлары акчасын җәлеп итеп финананслана торган капиталь төзелеш объектларына карата, – Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пунктының икенче абзацы, $78^3$ статьясының 2 пункты яки 80 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә кабул ителгән һәм капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яки күздә тотылган (чик) бәясе һәм егәрлеге турындагы мәгълүматларны үз эченә алган Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең иң югары органы норматив хокукый акты яки җирле муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты);

17. Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге һәм (яисә) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына, шул исәптән төзелеше федераль бюджет акчасын җәлеп итеп финанслана торган объектларга карата, – Татарстан Республикасының, тиешенчә, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар;

18. төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасын җәлеп итеп (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акча җәлеп итмичә) финанслана торган капиталь төзелеш объектларына карата, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең капиталь төзелеш объектына капитал салуны гамәлгә ашыру турындагы карары;

19. федераль максатчан программалар составындагы чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләгәндә – капиталь төзелеш объекты буенча тиешле федераль максатчан программасы кушымтасында китерелгән методикада билгеләнгән тәртиптә чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләү тәртибен билгеләүче методика буенча кабул ителгән, чарага (эреләндерелгән инвестиция проектына) керүче капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яисә күздә тотылган смета (чик дәрәҗә)

бәясе һәм егәрлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган карар;

19.1. әлеге бүлекнең 14-19 пунктларында күрсәтелгән карарлар (актлар) булмаган очракта, шулай ук капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча проект документларында күрсәтелгән смета бәясе капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне арттырып җибәргән очракта, – Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына финанслау планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (иң югары дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның)), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек өлеше 50 проценттан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчасы, шулай ук әлеге юридик затлар акчасы хисабына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге объектлар өчен), яисә дәүләт корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан башкарылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне раслый торган, капиталь төзелеш объекты төзүне, үзгәртеп коруны бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотылган финанслау чыганаклары яисә бюджетка карамаган чыганаклар турындагы мәгълүматны үз эченә алган хаты;

20. хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләү, мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасы бәяләмәләре реестрына кертелгән сәнәгый куркынычсызлык экспертизасының уңай бәяләмәсен теркәп, әгәр хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләүне әзерләү һәм

мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасын уздыру «Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында»гы федераль законда каралган булса;

21. федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты) – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты);

22. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;

23. вазыйфаи затның дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә юридик зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган ышаныч кәгазе (әлеге бүлекнең 19.1 һәм 21 пунктларында каралган очракларда күрсәтелә).

II. Бер үк вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәнең 27 пунктындагы «а» пунктчасында каралган бәяләү өлешендә проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә (шул исәптән документлардагы бүлекләрнең составына һәм эчтәлегенә карата да)

капиталь төзелеш объектына проект документлары. Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына дәүләт экспертизасын кабат уздыру өчен электрон формада тулы күләмендә тапшырыла торган проект документларына карата беренче мәртәбә (кабат уздырыла торганыннан алда) дәүләт экспертизасын уздырган оешмага электрон формада документлар тапшырылган очракта, проект документларының үзгәрешләр кертелгән өлеше тапшырыла;

3. проектлауга бирем;

4. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән күрсәтелгән нәтиҗәләр составына карата да) нигезендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

5. инженерлык эзләнүләрен үтәү биреме;

6. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

7. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экологик экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрелгән очракта, дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;

8. дәүләт катнаша торган зур инвестиция проектына гавами технологик аудит уздырылуы турында уңай җыелма бәяләмә (Россия Федерациясе законнары нигезендә гавами технологик һәм бәя аудитын уздыру мәҗбүри булып торса) яки үзенә карата капиталь төзелеш объектын проектлау, төзү һәм файдалануга кертү эшләрен бер үк вакытта башкару предметыннан гыйбарәт контрактны төзү планлаштырылган капиталь төзелеш объектын оештыру буенча инвестиция проектына гамәлгә ашырыла торган инвестицияләрне нигезләү һәм, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә мондый нигезләүне әзерләү һәм аңа технологик һәм бәя аудиты уздыру мәҗбүри булган очракта, инвестицияләрне нигезләүгә технологик һәм бәя аудиты бәяләмәсе;

9. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

10. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48

статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

11. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла).»;

12. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ.

13. хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләү, мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасы бәяләмәләре реестрына кертелгән сәнәгый куркынычсызлык экспертизасының уңай бәяләмәсен теркәп, әгәр хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләүне әзерләү һәм мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасын уздыру «Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль законда каралган булса;

14. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге

органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.

III. Проект документларын дәүләт экспертизасына җибәргәнчегә кадәр инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын үткәрү өчен тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән күрсәтелгән нәтиҗәләр составына карата да) нигезендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

3. инженерлык эзләнүләрен үтәү биреме;

4. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

5. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

6. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла);

7. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;

8. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.

IV. Яңадан кулланыла торган проект документларыннан файдаланып әзерләнгән проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә бер үк вакытта дәүләт экспертизасы уздыру өчен тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә (шул исәптән документлардагы бүлекләрнең составына һәм эчтәлегенә карата да) капиталь төзелеш объектына проект документлары. Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына дәүләт экспертизасын кабат уздыру өчен электрон формада тулы күләмендә тапшырыла торган проект документларына карата беренче мәртәбә (кабат уздырыла торганыннан алда) дәүләт экспертизасын уздырган оешмага электрон формада документлар тапшырылган очракта, проект документларының үзгәрешләр кертелгән өлеше тапшырыла;

3. смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эш күләмнәре исемлекләре;

4. проектлауга бирем;

5. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән күрсәтелгән нәтиҗәләр составына карата да) нигезендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

6. инженерлык эзләнүләрен үтәү биреме;

7. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи

һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

8. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экологик экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасын үткәрү очрагында дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

9. дәүләт катнаша торган зур инвестиция проектына гавами технологик аудит уздырылуы турында уңай җыелма бәяләмә (Россия Федерациясе законнары нигезендә гавами технологик һәм бәя аудитын уздыру мәҗбүри булып торса) яки үзенә карата капиталь төзелеш объектын проектлау, төзү һәм файдалануга кертү эшләрен бер үк вакытта башкару предметыннан гыйбарәт контрактны төзү планлаштырылган капиталь төзелеш объектын оештыру буенча инвестиция проектына гамәлгә ашырыла торган инвестицияләрне нигезләү һәм, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә мондый нигезләүне әзерләү һәм аңа технологик һәм бәя аудиты уздыру мәҗбүри булган очракта, инвестицияләрне нигезләүгә технологик һәм бәя аудиты бәяләмәсе;

10. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

11. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле теренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник

заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

12. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла);


19. вазыйфаи затның дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә юридик зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган ышаныч кәгазе (әлеге бүлекнең 15.1 һәм 17 пунктларында каралган очракларда күрсәтелә).

IX. Капиталь төзелеш объектын сүтүнең смета бәясен билгеләү төгәллеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен (сүтү капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору белән бәйле булмаган очракта) тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эш күләмнәре исемлекләре;

3. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

4. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны

үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

5. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

6. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла);

7. капиталь төзелеш объектын сүтү буенча эшләрне оештыру проекты;

8. капиталь төзелеш объектын сүтү өчен смета;

9. капиталь төзелеш объектын техник регламентлардагы таләпләр, санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен куллану өлкәсендәге эшчәнлекнең куркынычсызлык таләпләре, сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру таләпләре нигезендә тикшерү нәтиҗәләре һәм материаллары;

10. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;

11. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен

гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү.

X. Капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонтның смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен (мондый эшләр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору белән бәйле булмаган очракта) тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә (шул исәптән документлардагы бүлекләрнең составына һәм эчтәлегенә карата да) капиталь төзелеш объектына проект документлары. Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына дәүләт экспертизасын кабат уздыру өчен электрон формада тулы күләмендә тапшырыла торган проект документларына карата беренче мәртәбә (кабат уздырыла торганыннан алда) дәүләт экспертизасын уздырган оешмага электрон формада документлар тапшырылган очракта, проект документларының үзгәрешләр кертелгән өлеше тапшырыла;

3. смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эш күләмнәре исемлекләре;

4. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

5. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

6. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки)

инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнүләре өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

7. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла), проект документларының һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләренең төзүчегә (техник заказчыга) тапшырылуын раслый торган документ;

8. Федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи заты) – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты).

9.төзүче яисә техник заказчы тарафыннан расланган һәм, тикшерү датасына карата мондый җитешсезлекләрнең сыйфат һәм сан ягыннан характеристикаларын күрсәтеп, нигез, төзелеш конструкцияләре, инженер-техник тәэмин итү системалары һәм инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре җитешсезлекләре исемлеген үз эченә алган акт.

XI. Дәүләт экспертизасын кабат үткәрү өчен тапшырыла торган документлар:

1. дәүләт экспертизасын кабат үткәрү турында гариза;

2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә (шул исәптән документлардагы бүлекләрнең составына һәм эчтәлегенә карата да) капиталь төзелеш объектына проект документлары. Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларына дәүләт экспертизасын кабат уздыру өчен электрон формада тулы күләмендә тапшырыла торган проект документларына карата беренче мәртәбә (кабат уздырыла торганыннан алда) дәүләт экспертизасын уздырган оешмага электрон формада документлар тапшырылган очракта, проект документларының үзгәрешләр кертелгән өлеше тапшырыла;

3. смета исәпләмәләрендә исәпкә алынган эш күләмнәре исемлекләре;

4. проектлауга бирем;

5. проектның баш инженеры имзалаган белешмә;

6. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр (шул исәптән күрсәтелгән нәтиҗәләр составына карата да) нигезендә инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

7. инженерлык эзләнүләрен үтәү биреме;

8. экспертизаның беренчел бәяләмәләре;

9. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе;

10. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экологик экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрелгән очракта, дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;

11. дәүләт катнаша торган зур инвестиция проектына гавами технологик аудит уздырылуы турында уңай җыелма бәяләмә (Россия Федерациясе законнары нигезендә гавами технологик һәм бәя аудитын уздыру мәҗбүри булып торса) яки үзенә карата капиталь төзелеш объектын проектлау, төзү һәм файдалануга кертү эшләрен бер үк вакытта башкару предметыннан гыйбарәт контрактны төзү планлаштырылган капиталь төзелеш объектын оештыру буенча инвестиция проектына гамәлгә ашырыла торган инвестицияләрне нигезләү һәм, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә мондый нигезләүне әзерләү һәм аңа технологик һәм бәя аудиты уздыру мәҗбүри булган очракта, инвестицияләрне нигезләүгә технологик һәм бәя аудиты бәяләмәсе;

12. мөрәҗәгать итүченең төзүче, техник заказчы, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда (мөрәҗәгать итүче техник заказчы, төзүче, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48

статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат булып тормаса), инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүче зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документлар, аларда дәүләт экспертизасы уздыру турындагы килешүне төзү, аны үзгәртү, үтәү, таркату вәкаләтләре махсус әйтелгән булырга тиеш;

13. архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзеннән-үзе көйләнә торган оешма әгъзалары реестрыннан өземтә, аның әгъзасы булып проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен башкару буенча эшләрне башкаручы, проект документларын тапшыру датасына һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүче, техник заказчыга, инженерлык эзләнүләрен үтәүне тәэмин итүче затка, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда проект документларын әзерләүне тәэмин итүче затка, яисә төзүче, башка зат булса, дәүләт экспертизасына документлар тапшыру датасына РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясындагы $1^1$ һәм $1^2$ өлешләре белән бер үк вакытта проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә архитектура-төзелеш проектлау һәм (яки) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада проект документларын әзерләү һәм (яки) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эш башкаручының әгъзасы таләп ителгән очракта тапшырыла). Проект документлары һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләре төзүчегә 2017 елның 1 июленә кадәр тапшырылган очракта, эшләр башкаручы затны проект документларын әзерләү буенча эшләрнең тиешле төренә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә кертү турында проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен төзүчегә (техник заказчыга) тапшыру датасына гамәлдә булган үзкөйләнешле оешма тарафыннан бирелгән таныклыклар тапшырыла, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый эшләргә рөхсәт алу 2017 елның 1 июленә кадәр мәҗбүри булып торган булса;

14. РФ Шәһәр төзелеше кодексының 47 статьясының $2^1$ өлешендә һәм 48 статьясының $4^1$ өлешендә каралган нигезләрдә, проект документларын һәм (яисә) инженерлык эзләнүләрен үтәү буенча эшләр башкаручы зат өчен аның архитектура-төзелеш буенча проектлау өлкәсендә һәм (яисә) инженерлык эзләнү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуы таләп ителмәвен раслаучы документлар (үзкөйләнешле оешма әгъзалары реестрыннан өземтә – документ тапшырылмаган очракта тапшырыла);

15. проект документларын һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен техник заказчыга яки, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ һәм $1^2$ өлешләрендә каралган очракларда, инженерлык эзләнү һәм (яки) проект документларын әзерләү эшләрен башкаручы затка тапшыруны раслый торган документ;

16. хосусый смета нормативларын эшләү һәм куллану турында Россия Федерациясе Хөкүмәте карары турында белешмәләр (әгәр мондый карар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документлары бүлекләре составы һәм аларның

эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары белән расланган Проект документлары бүлекләренең составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турындагы нигезләмәнең 30 пункты нигезендә кабул ителгән булса);

17. Россия Федерациясенең дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына карата – Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый акты яисә федераль бюджет акчасын төп бүлүченең бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм тормышка ашыру турында, капиталь төзелеш объектына капитал кертүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү турында карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль максатчан программа раслау турында норматив хокукый акты;

18. дәүләт яки муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт яки муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт компанияләрен һәм корпорацияләрен дә кертеп, булып тормаган юридик затларның төзелеше, үзгәртеп корылышы Татарстан Республикасы бюджетлары акчасын җәлеп итеп финанансланa торган капиталь төзелеш объектларына карата, – Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пунктының икенче абзацы, $78^3$ статьясының 2 пункты яки 80 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә кабул ителгән һәм капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яки күздә тотылган (чик) бәясе һәм егәрлеге турындагы мәгълүматларны үз эченә алган Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең иң югары органы норматив хокукый акты яки җирле муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты);

19. Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге һәм (яисә) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына, шул исәптән төзелеше федераль бюджет акчасын җәлеп итеп финанслана торган объектларга карата, – Татарстан Республикасының, тиешенчә, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар;

20. төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасын җәлеп итеп (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан акча җәлеп итмичә) финанслана торган капиталь төзелеш объектларына карата, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең капиталь төзелеш объектына капитал салуны гамәлгә ашыру турындагы карары;

21. федераль максатчан программалар составындагы чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләгәндә – капиталь төзелеш объекты буенча тиешле федераль максатчан программасы кушымтасында китерелгән методикада билгеләнгән тәртиптә чараларны (эреләндерелгән инвестиция проектларын) җентекләү тәртибен билгеләүче методика буенча кабул ителгән, чарага (эреләндерелгән инвестиция проектына) керүче капиталь төзелеш объекты турында, шул исәптән аның смета яисә күздә тотылган смета (чик дәрәҗә) бәясе һәм егәрлеге турында мәгълүматларны үз эченә алган карар;

21.1 әлеге бүлекнең 16-21 пунктларында күрсәтелгән карарлар (актлар)

булмаган очракта, шулай ук проект документларында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясе капиталь төзелеш объектына карата тиешле карарда (актта) билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне арттырып җибәрә икән, – Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет акчаларын төп бүлүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органы яки оешма җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең өлеше 50 процентан артык булган юридик зат җитәкчесенең (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслауны федераль бюджеттан бирелә торган акчалар, әлеге юридик затлар акчасына гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (иң югары дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), җирле администрация башлыгының (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек тарафыннан оештырылган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 процентан артык булган юридик зат җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, муниципаль бюджетлар акчалары хисабыннан гамәлгә ашыру планлаштырыла торган объектлар өчен, шулай ук финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге, муниципаль милектәге, шул исәптән төзелешен, үзгәртеп корылышын финанслау әлеге юридик затларның акчалары хисабына планлаштырыла торган объектлар өчен), яисә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) (капиталь төзелеш объектлары Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын җәлеп итмичә генә дәүләт компаниясе һәм корпорациясе акчалары хисабыннан төзелгән, үзгәртеп корылган очракта) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча гаризада күрсәтелгән смета бәясен яки күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәяне раслый торган, капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны финанслау буенча бюджет турындагы законда (карарда) каралган, күздә тотыла торган чыганаклар яисә бюджетка карамаган чыганаклар турында мәгълүматны үз эченә алган хаты;

22. хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләү, мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасы бәяләмәләре реестрына кертелгән сәнәгый куркынычсызлык экспертизасының уңай бәяләмәсен теркәп, әгәр хәтәр җитештерү объектының куркынычсызлыгын нигезләүне әзерләү һәм

мондый нигезләүгә сәнәгый куркынычсызлык экспертизасын уздыру «Хәтәр җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында»гы федераль законда каралган булса;

23. федераль башкарма хакимият органы җитәкчесенең (яисә ышаныч нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның), Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) – тиешле бюджет акчаларын баш бүлүче булып торган затның капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен һәм аның егәрлеген төзелеш этаплары буенча бүлүне күздә тоткан этаплап башкару турында барлык этаплар буенча объектны төзү, үзгәртеп коруның гомуми смета бәясенең капиталь төзелеш объектының гомуми егәрлеген саклап, объект төзелешенең билгеләнгән күздә тотылган (чик дәрәҗә) бәясен арттырмавын раслый торган карары (акты) яисә, төзелеше, үзгәртеп корылышы дәүләт компанияләре һәм корпорацияләре акчасы хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның аерым этабына карата проект документлары әзерләнгән очракта, – дәүләт компаниясе һәм корпорациясе җитәкчесенең (яисә ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи затның) әлеге карары (акты);

24. дәүләт (муниципаль) милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырган очракта, дәүләт (муниципаль) контрактларны тиешле гавами-хокукый оешма исеменнән төзү һәм үтәү буенча дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге органнар затыннан дәүләт (муниципаль) заказчылар булып торган дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), дәүләт бюджетка карамаган фондлар белән идарә итү органы, җирле үзидарә органы һәм әлеге органнар аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бюджет һәм автоном учреждениеләр белән яки әлеге органнар аларга карата тиешле гавами-хокукый оешманың мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра торган дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр белән (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының $1^1$ өлешендә каралган очракта) төзелгән килешү;

25. вазыйфаи затның дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә юридик зат исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган ышаныч кәгазе (әлеге бүлекнең 21.1 һәм 23 пунктларында каралган очракларда күрсәтелә).

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
4 нче кушымта

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе директорына

Җибәрелү номеры ____, ____________________ ел.

Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрү турында гариза*(1)

________________________________________________________________

(дәүләт экспертизасы үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче зат)

дәүләт экспертизасы үткәрү өчен документлар җибәрә

________________________________________________________________

(дәүләт экспертизасы объекты күрсәтелә:

- бер үк вакытта проект документлары һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәнең 27 пунктындагы «а» пунктчасында каралган бәяләү өлешендә бер үк вакытта проект документлары һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

- проект документлары дәүләт экспертизасына җибәрелер алдыннан инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

- бер үк вакытта яңадан кулланыла торган проект документларыннан файдаланып әзерләнгән проект документлары һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;

- инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәргәннән соң проект документлары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәнең 27

пунктындагы «а» пунктчасында каралган өлешендә, инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздырылганнан соң, проект документлары;
- капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп коруның смета бәясен билгеләүнең төгәллеген тикшерү өлешендә проект документлары;
- капиталь төзелеш объектын сүтүнең смета бәясен билгеләү төгәллеген тикшерү өлешендә проект документлары (сүтү капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп кору белән бәйле булмаган очракта);
- капиталь төзелеш (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау буенча үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, эшләр башкару) объектына карата капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау буенча смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документлары (әгәр мондый эшләр капиталь төзелеш объектын төзү яки үзгәртеп коруга бәйле булмаса) (алга таба – капиталь төзелеш объtrns)

______________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының исеме*(2))

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
- төзелеш
- үзгәртеп кору
- капиталь ремонтлау
- сүтү
- мәдәни мирас объектларын саклау эшләре

______________________________________________________________________
(кирәкмәгәнен сызарга)

I. Капиталь төзелеш объекты турында идентификация белешмәләре:

а) төзелеше күздә тотылган объект атамасы

______________________________________________________________________

(проект документларын әзерләү өчен нигез булган документ нигезендә)

б) капиталь төзелеш объектының функциональ билгеләнеше турында белешмәләр: ______________________________________________________
җитештерү/җитештерү булмаган билгеләнештәге объект;
______________________________________________________________________;
линияле объект

в) капиталь төзелеш объектының почта (төзелеш) адресы:
______________________________________________________
______________________________________________________________________;

г) капиталь төзелеш объектының төп техник-икътисадый күрсәткечләре

(мәйданы, күләме, озынлыгы, катлар саны, җитештерү куәте һәм башкалар): ____________________________________

______________________________________________________________________;

д) чикләрендә капиталь төзелеш объекты урнашкан яки урнаштыру планлаштырыла торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) кадастр номеры: ____________________________________________

______________________________________________________________________;

е) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документларны раслау номеры һәм датасы: _________________

______________________________________________________________________;

ж) линияле объектның проект документларын әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру буенча документлар расланган номер һәм документның датасы (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш) ___________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________.

II. Эшләрне башкаручылар – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 1.1 һәм 1.2 өлешләрендә каралган очракларда, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашырган һәм инженерлык эзләнүләрен башкарган затлар, инженерлык эзләнүләрен башкаруны һәм (яки) проект документларын әзерләүне тәэмин иткән затлар турында идентификация белешмәләре*(3):

а) юридик затның тулысынча аталышы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта): __________________________________

______________________________________________________________________;

б) шәхси эшкуарның мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетының иминият номеры:

в) юридик затның урнашу урыны һәм адресы йә шәхси эшкуарның почта адресы: _____________________________________

___________________________________________________________________;*(4)

г) юридик затның ИНН: ___________________________________;

д) юридик затның яисә шәхси эшкуарның ОГРН:

______________________________________________________________________;

е) юридик затның КПП: ___________________________________________;

ж) юридик затның яки шәхси эшкуарның электрон почта адресы (булган очракта): ______________________________________

______________________________________________________________________;

III. Төзүче, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 1.1 һәм 1.2 өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү башкарылуын һәм

(яки) проект документларын әзерләүне тәэмин иткән зат турында идентификация белешмәләре:*(5):

а) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының тулы атамасы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта):

______________________________________________________________________

б) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының урнашу урыны һәм адресы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның почта адресы: ______________________________________

______________________________________________________________________;

в) физик затның яки шәхси эшкуарның мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетының иминият номеры:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________;

г) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы ИНН:

______________________________________________________________________;

д) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә

шәхси эшкуарның ОГРН: ____________________________________;

е) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының КПП:

______________________________________________________________________;

ж) электрон почта адресы (булган очракта): ___________________________

______________________________________________________________________.

Техник заказчы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 1.1 һәм 1.2 өлешләрендә каралган очракларда инженерлык эзләнү башкарылуын һәм (яки) проект документларын әзерләүне тәэмин иткән зат турында идентификация белешмәләре*(6):

а) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының тулы атамасы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта):

______________________________________________________________________;

б) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының урнашу урыны һәм адресы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның почта адресы:

______________________________________________________________________;

в) физик затның яки шәхси эшкуарның мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетының иминият номеры:

______________________________________________________________________;

г) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә

органы ИНН:

______________________________________________________________________;

д) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә шәхси эшкуарның ОГРН:

______________________________________________________________________;

е) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының КПП:

______________________________________________________________________;

ж) электрон почта адресы (булган очракта): ____________________________

______________________________________________________________________;

IV. Мөрәҗәгать итүче турында идентификация белешмәләре*(5)

а) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының тулы атамасы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта):

______________________________________________________________________;

б) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының урнашу урыны һәм адресы яисә физик затның яисә шәхси эшкуарның почта адресы:

______________________________________________________________________;

в) физик затның яки шәхси эшкуарның мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси счетының иминият номеры:

______________________________________________________________________;

г) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы ИНН: ______________________________________________________;

д) юридик зат, дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә шәхси эшкуарның ОГРН: ______________________________;

е) юридик затның, дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының КПП:

______________________________________________________________________;

ж) электрон почта адресы (булган очракта):

______________________________________________________________________;

з) телефон номеры:

_____________________________________________________.

V. Кабат кулланыла торган, икътисадый нәтиҗәле проект документларын куллану турында (кулланмау сәбәпләре турында) белешмәләр:

Тапшырылган проект документлары кабат кулланыла торган, икътисадый нәтиҗәле проект документларын кулланып әзерләнгән.*(7)

Тапшырылган проект документларын әзерләгәндә кабат кулланыла торган проект документлары кулланылмады, чөнки: ______________________________

______________________________________________________________________;*(8)

(кабат кулланыла торган проект документларыннан файдаланмау сәбәбе күрсәтелә, мисал өчен:

- проект документлары төзелеше федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек оештырган юридик зат, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек өлеше 50 процентган артык булган юридик зат тарафыннан тәэмин ителми торган капиталь төзелеш объектына карата әзерләнгән;

- билгеләнеше, проект егәрлеге, табигый һәм төзелешне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориянең башка шартларына аналогик капиталь төзелеш объектын төзү өчен кулланылырга мөмкин булган, кабат кулланыла торган проект документлары юк;

- проект документлары капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен башкару максатларында әзерләнгән)

VI. Проектның тулы бәясенә процент нисбәтендә финанслау чыганагы һәм финанслау күләме турында белешмәләр:

Капиталь төзелеш объектын төзүне (үзгәртеп коруны, капиталь ремонтны) финанслауны түбәндәгеләр акчасы хисабына гамәлгә ашыру планлаштырыла:

___

(финанслау чыганагы күрсәтелә: төзелешнең тулы бәясенә процент нисбәтендә, документларның номерын һәм датасын күрсәтеп:

- федераль бюджет акчалары;
- Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары;
- җирле бюджет акчалары;
- Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан төзелгән юридик затлар акчалары;
- устав (җыелма) капиталларында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең өлеше 50 процентган артык булган юридик затлар акчалары;
- төзүченең шәхси акчалары)

VII. Капиталь төзелеш объектының смета яки фаразланыла торган (чик дәрәҗә) бәясе турында белешмәләр

___

___

(капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләренең смета бәясе турында һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы, шулай ук Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек оештырган юридик затлар акчасы, устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектының, муниципаль берәмлекнең өлеше 50 процентган артык булган юридик затларның акчасы (мең сумнарда) хисабына финанслау өлеше турындагы белешмәләр, шулай ук әлеге акчалар хисабына финанслау күләме (төзелешнең тулы бәясенә процент нисбәтендә) турындагы белешмәләр күрсәтелә)

VII. 1. Капиталь төзелеш объектын төзелеше, үзгәртеп корылыгы Россия Федерациясен пространстволы үстерү стратегиясе нигезендә магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтү максатларында гамәлгә ашырыла торган федераль, региональ яки җирле әһәмияттәге транспорт объектларына кертү

турында белешмәләр

______________________________________________________________________

_____________________________________________________________________.

VIII. Бүтән белешмәләр:

Төзүченең вәкаләтләрен капиталь төзелеш объектын төзү (үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау эшләрен) гамәлгә ашыру планлаштырылган җир кишәрлегенә (җир кишәрлекләренә) карата хокуклар турындагы документлар белән раслыйбыз: ______________________________

______________________________________________________________________

_____________________________________________________________________.

Югарыда аталган капиталь төзелеш объекты буенча проект документларына карата элегрәк дәүләт экспертизасы уздырылды, аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирелде _______________________________________________

_____________________________________________________________________.*(9)

(дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең датасы һәм номеры, кем тарафыннан бирелгән)

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрү очрагында дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе: __________

______________________________________________________________________

(бәяләмә датасы һәм номеры, кем тарафыннан бирелгән)

_____________________________________________________________________.

(яки булмавын язмача нигезләү)

Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт экологик экспертизасына тиешле проект документларына дәүләт экспертизасы үткәрелгән очракта, дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе:

______________________________________________________________________

(бәяләмә датасы һәм номеры, кем тарафыннан бирелгән)

_____________________________________________________________________.

(яки булмавын язмача нигезләү)

*(1) Гаризада мәҗбүри тәртиптә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документларына һәм инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәдә дәүләт экспертизасына тапшыру өчен каралган белешмәләр, шулай ук дәүләт экспертизасы уздыру турында килешү төзү өчен кирәкле белешмәләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 24 июлендәге 878 номерлы карарында каралган реестрны формалаштыру өчен кирәкле белешмәләр күрсәтелә

*(2) Проект документларын әзерләү өчен нигез булган документ нигезендә

*(3) Проект документларын әзерләгән һәм (яки) инженерлык эзләнү нәтиҗәләрен

башкарган берничә зат булган очракта, мондый һәр зат буенча белешмәләр китерелә, шул ук вакытта төзүче (техник заказчы) белән төзелгән килешү нигезендә тиешле эшләрне башкарган зат беренче итеп күрсәтелә

*(4) Биредә һәм алга таба – юридик затның урнашкан урыны һәм адресы Россия Федерациясе Граждан кодексының 54 статьясының 2 һәм 3 өлешләрендәге таләпләрне исәпкә алып күрсәтелә

*(5) Төзүче (техник заказчы) белән мөрәҗәгать итүче бер үк зат булган очракта күрсәтелә

*(6) Әгәр төзүче белән техник заказчы бер үк зат булмаса, аларның һәркайсы буенча белешмәләр китерелә

*(7) Дәүләт экспертизасын уздыру өчен кабат кулланыла торган проект документларыннан файдаланып әзерләнгән проект документлары тапшырылган очракта күрсәтелә

*(8) Дәүләт экспертизасын уздыру өчен кабат кулланыла торган проект документларыннан файдаланмыйча әзерләнгән проект документлары тапшырылган очракта күрсәтелә

*(9) Тиешле капиталь төзелеш объекты буенча проект документларына карата элегрәк дәүләт экспертизасы уздырылып, аның нәтиҗәсендә тиешле бәяләмә бирелгән очракта күрсәтелә.

Проект документларына һәм
инженерлык эзләнү нәтиҗәләренә
дәүләт экспертизасы буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
4.1 кушымта

«Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе директорына ____________

Җибәрелү номеры ____, ___________________ ел.

Эксперт тарафыннан бәяләү өчен килешү төзү турында гариза[1]

______________________________________________________________

(дәүләт экспертизасы үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче зат)

эксперт тарафыннан бәяләү өчен түбәндәгегә карата проект документларын җибәрә

______________________________________________________________

(дәүләт экспертизасы объекты күрсәтелә)

капиталь төзелеш (үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау, сүтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен) саклау буенча эшләр башкаруга) (алга таба – капиталь төзелеш объекты) карата кулланыла торган.

(капиталь төзелеш объектының исеме[2])

- төзелеш
- үзгәртеп кору
- капиталь ремонтлау
- сүтү
- мәдәни мирас объектларын саклау эшләре

______________________________________________________________

